

ISSN 0206—4197

АЗАТ ХАТЫН

5/87

sh

МӘҢГЕЛЕК УТ ЯНЫНДА





ТЫНЫЧЛЫК — БӨЕК СҮЗ

Безнең әни белән әтиебез 1942 елда берсе артыннан берсе вафат булдылар. Бу вакытта олы абыебыз Тимерхан сугышта иде. Без кечерәкләр — Гөлсем, Мөхәммәтҗан һәм Суфия әле үзе дә үсмерлектән чыкмаган апабыз Рокыя тәрбиясендә калдык. Без ул елларда Чимкент шәһәрендә яши идек. Бераз үсә төшкәч, мин энем Мөхәммәтҗан белән элек әти белән олы абыебыз Тимерхан эшләгән заводка эшкә урнаштык. Яшь булсак та, илебез азатлыгы өчен безнең хезмәтнең кирәклеген тоеп, тырышып эшләдек. Чөнки ул чакларда эшче кулы бик кирәк иде.

Без үз өебез белән яшәдек. Сыер асрадык, йорт тирәсендә бәрәңге, кәбестә, кукуруз ише әйберләр үстердек. Кечкенәдән эшкә өйрәнеп үстек. Рокыя апабыз иң олысы буларак, һәрберебезгә көченә карап эшен таба, бик оста кулда тота иде.

Олы абыебыз Тимерхан сугыштан җиңү яулап исән-сау әйләнеп кайтты. Ул кайткач, Рокыя апага да, безгә дә зур терәк булды.

Үсеп җиткәч, биш туган төрлебез төрле шәһәрләргә таралыштык. Барыбызның да гаиләләре бар, инде оныкларыбыз үсеп килә. Төрле шәһәрләрдә булсак та, бер-беребезне ташламыйбыз, бик тату яшибез. Абыебыз Тимерхан белән Рокыя апабыз булмаса, нишләр идек икән без, дип уйлыйбыз. Алар тәрбиясе, алар җылысы безгә тормышта үз урыныбызны табарга ярдәм итте. Сугыш чоры авырлыгы иң башлап алар җилкәсенә төште. Үзләренә кыен булса да, безгә ятимлекне сиздермәскә тырыштылар. Аларга карата хөрмәтебез һәм рәхмәтебез чиксез безнең.

Мин бүгенге көндә өч бала анасы. Балаларыбызның өчесе дә югары белем алды. Тыныч, мул тормышта шатланышып яшибез. Дөньялар тыныч, имин булсын да балаларыбыз без күргән сугыш ачысын татымасыннар, бәхетле булсыннар иде.

Гөлсем ГЫЙМАЕВА.
Лениногорск шәһәре.


Тугызынчы Май.
Н. ТУГАНОВ фотосы.

Журналның узган елгы 10 нчы санында М. Шәйдуллованың «Тынычлык өчен көрәшик!» дигән мәкаләсен укып бик дулкынландым. Мин пенсионер кеше. Тынычлык өчен көрәшүчеләр сафында буласым килә. Картайсам да, сәламәтлегем булмаса да читтә гамьсез гомер кичерәсем килми. Җир йөзендә тынычлык булсын. Сугышлар булмасын, дигән изге теләкләр белән яшим. Тынычлык өчен көрәшүчеләр исемлегенә мине дә теркәгез. Мин тынычлык фондына 100 сум акча күчердем инде.

Таһирә БАДЫЙКОВА.
Казан.

Р. МӨХӘММӘТҖАНОВ һәм В. ПАВЛОВ фотолары.

© «Азат хатын», 1987 ел.

Матбугат отличнигы

КУЛЪЯЗМАДАН КИТАП ЯСЫЙ УЛ



Ел саен ничәмә-ничә йөз әсәрне укучылар күңеленә илтүчеләр хакында сөйләгәндә, без еш кына китапны китап рәвешенә китерүче, аңа «тере суы» бөркүче өлкән техник редактор Әнисә Салиховна Трофимованы да искә төшерәбез.

Әйтик, язучы күп еллык хезмәтенең нәтиҗәсе булган кулъязмасын нәшриятка күтәреп килде, ди. Аны редактор редакцияләп, кабат машинисткалардан бастырып, корректорлардан укытып алса да, бу әле китап түгел, ә аның юл башы гына. Кулъязма-оригиналны типографиягә озатыр алдыннан аның рәссам тарафыннан эшләнгән бизәкле тышлыгы, титул бите, күплләгән рәсем-иллюстрацияләре, ә инде китап дәреслек яки фәнни хезмәт булырга тиеш булса, күпләгән таблицалар, диаграммалар, төрле-төрле сызымнар, формулалар — кыскасы, кулъязманың бик күп, бик күп иярченнәре техник редактор өстәленә килеп ята. Һәм менә ул, миллиметрдан да нечкәрәк сызыкларга бүлгәләнгән линейкасын кулына тотып, таралып яткан әлеге кисәкләрне оештырып, бер калыпка туплау, алардан китап кадәр китап ясау турында тирән уйга кала. Китапның форматы кулаймы? Кырыкмаса-кырык төрле шрифт арасыннан кайсын сайласа килешлерәк булыр? Рәсем яки таблицаларны нинди тәртиптә урнаштырырга? Кәгазьнең ниндиенә басканда төсләр-буяулар гаммасына зыян килмәс? Техник редакторның бөтен уе, бөтен барлыгы белән китап дөньясына күчкән мизгелләре бу.

Менә утыз елдан артык инде Әнисә ханым, конструктордан бер дә кимен куймыйча, китаплар төзи, аларның һәрбер битен, һәр сыңар хәрефен диярлек күзеннән үткәрә.

Күз ул кеше акылының тәрәзәсе, диләр. Мәшәкатьле тормышыбызның җил-давылы да, карлы-бозлы яңгыры да китереп кага аны. Ләкин кеше өчен иң кадерле нәрсәләрнең берсе — китап иҗат иткәндә бөтен кайгыңны да эчеңә йотарга мәҗбүр син, һәм Әнисә онытылып, укучыларның күзләрен кайгыртып, китап укыганда ялыкмасыннар өчен, текстларын мөмкин хәтле тыгызламаска, шул ук вакытта китап битләрендә мәгънәсез «ак кырлар» калдырмаска тырыша. Әнә шулар исәбенә ул тонналап-тонналап кәгазьне янга калдыра. Ә сабыйлар китабын чыгарганда, баласына куркыныч янагандай, әнкә болан кебек аеруча сагаеп кала. Кәгазьгә экономия ясыйм дип, китап битләрен текст белән шаплап тутыра башласаң, бала күзенә көч киләчәк.

Хезмәте барның хөрмәте бар. Техник редакция мөдире, матбугат отличнигы, хезмәт ветераны Әнисә Салиховна өчен нәшрият коллективында мактау сүзләрен ишетү, Татарстан яки РСФСР матбугат оешмаларының асыл эчтәлекле грамоталарын яки дипломнарын алып тору бер дә ят нәрсә түгел. Ләкин Яңа ел алдыннан гына үз исеменә килеп төшкән дипломнар аны бик тә дулкынландырды. Чөнки аларда Әнисә Салиховнага борынгы поэзиябезнең җәүһәрләре — Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабын (татар һәм рус телләрендә), Утыз Имәнинең шигырьләр һәм поэмалар җыентыгын чын мәгънәсендә үрнәк итеп чыгарганы өчен олы рәхмәт белдерелгән иде. Әйе, ул җыентыкларны төзүче авторлар, әдәби редакторлар белән бергә Әнисәбезнең дә җимешләре иде шул бу.

Үсмер чагында кешеләрне сокландырып, җилкенә-җилкенә клуб сәхнәләрендә биегән кебек, тормыш һәм хезмәт сәхнәсендә дә үз номерын җиренә җиткереп башкара безнең Әнисә апабыз.

Суфия ӘХМӘТҖАНОВА.
Татарстан китап нәшриятының өлкән техник редакторы.
З. БӘШИРОВ фотосы.

«КАЛӘМ ОСТАЛАРЫ» ДИЛӘР БУ КЫЗЛАРЫБЫЗНЫ

Халыкара хатын-кызлар бәйрәме 8 нче Мартны каршы алганда Татарстан журналистлар союзы һәм «Азат хатын» журналы редакциясе хатын-кыз журналистлар өчен бәйрәм кичәсе үткәрде. Республика газеталары һәм журналлары редакцияләрендә эшләүче ир-егетләр аларны җыр, шигырь, шаян сүз белән тәбрикләделәр.

Телевидение комментаторы В. Булычев хатын-кызларны котлый.







В. ЗОТОВ фотолары.

ЯПЬ-ЯШЬ КЕНӘ БУЛСА ДА

Үтеп баручы санитария поезды Кострома шәһәре вокзалында туктап торган арада, поезд начальнигы урнашкан вагонга 18 яшьлек бер кыз сикереп менде һәм поездга эшкә алуларын үтенә башлады. Поезд начальнигы, медицина майоры Софья Николаевна беравык ни дип әйтергә дә белми торды. Санитаркалар кирәк кирәген дә, моңарчы белмәгән, күрмәгән япь-яшь кызны алу да тәвәккәллек сорый: поездга утырып йөрисе генә түгел бит, фронт тирәсендә дошман самолетлары һөҗүме астында калган чаклар да була, җимерелгән юлын да ремонтлыйсың, урманнан кисеп утынын да ташыйсың.

— Минем бертуган апам да сезнеке шикелле санитария поездында йөри,— дигәч, Софья Николаевна кызга өмет белән карый башлады. Кыз болай үзе тере күренә иде. Әнә шулай итеп, Рәхимә Зарипова 1943 елның язында 148 номерлы хәрби санитария поездына кабул ителә.

Рәхимәнең абыйлары Вазих белән Габделәхәт 1942 елда сугыш корбаннары булдылар. Алар өчен үч алырга дип, шул ук елны, Рәхимәнең апасы Рабига үзе теләп хәрби хезмәткә китә. Инде менә Рәхимә дә апасы юлын сайлый.

Санитария поезды, яраланган сугышчыларны төяп, тылга алып чыга. Җиңелрәк яралылар фронтка якынрак калдырылса, инде икенче тапкыр кулына корал алыр өметләре булмаганнарын Алма-Ата, Ташкент кебек калаларга кадәр кайтаралар иде.

Нинди генә авырлыклар очрамады фронт юлларында. Буг елгасы аша салынган күперне дошман җимереп киткән иде. Хәзер генә чуен күпер салып булмый бит. Вакытлыча агач күпер салдылар. Яралылар төялгән состав әнә шул күпер өстеннән үтте.

Санитария поездының экипажы 78 кешедән тора иде. Шулар арасында карт капитан Николай Федорович һәм сәламәтлекләре буенча фронт өчен яраксыз дип табылган ике ир бар. Калганнары — хатын-кызлар, Рәхимә исә аларның да иң яше иде.

Поезд экипажы тәүлекләр буе диярлек аяк өстендә. Бер станциядә, иңнәренә салып, азык-төлек әйберләре, медикаментлар төясәләр, икенчесендә паровозга ягу өчен утынын ташыдылар. Юлы җимерелсә дә, тимерюлчылар, саперлар килеп төзәткәнне генә көтеп ятмадылар, хәлдән килгәнчә үзләре тырыштылар. Ул чагында баштан кичкәннәрне, күргән авырлыкларны әйтеп-язып кына бетерерлекме?!

Бер бик шатлыклы вакыйга да булган икән әле. 1944 елның җәендә Львов шәһәре вокзалында ике санитария поезды кара-каршы очрашты. Берсе — тылга, икенчесе фронтка таба юл тота иде. Шул чакта әлеге поездларда хезмәт итүче Рабига белән Рәхимә Зариповалар бер-берсе белән күрештеләр. Сугыш юлларында туганнарның беренче һәм соңгы тапкыр очрашулары булды бу. Аннан соң сугыш бетеп, Костромага кайткач кына күрештеләр.

Сугыш беткән көнне — 9 Майны Рәхимә Берлинда каршылады. Мәскәүгә Советлар Союзы маршалы Г. Жуков һәм И. Коневлар белән бер поездда кайтты. 24 июнь көнне Мәскәүдә үткәрелгән хәрби парадта катнашты.

Рәхимә Зарипова — Балтач районының Шода авылында туган. Аларның семьясы Кострома шәһәренә күчеп киткән булган. Язмыш Рәхимәне сугыштан соң яңадан туган якка кайтарды. 1948 елда Чепья авылында тормышка чыгып, ул шунда төпләнеп калды.

Рәхимә Зарипова пенсиягә чыкканчы Чепья көнкүреш комбинатында 25 елдан артык тегүче булып эшләде. Намуслы хезмәте өчен Рәхимә бишьеллык ударнигы билгесе, күп кенә Почет грамоталары белән бүләкләнде. 1976 елда исеме көнкүреш хезмәте комбинатының Мактау китабына кертелде. Аның күкрәгендә сугышчан һәм юбилей медальләре балкый.

Рәхимә Зарипова хәзер ялда, мәктәп укучылары белән очрашуларда сугыш истәлекләрен сөйләп, укучыларга хәрби патриотик тәрбия бирә.

Ә. МӘРДӘНОВ.
Балтач районы.

РӘСЕМНӘРДӘ АНЫҢ ТОРМЫШЫ



Ватан өчен!

Рәсем. Каләм белән ясалып, акварель белән төсмерләр салынган өлкән яшьтәге хатын рәсеме. Сагышлы йөз. Әле һаман көчен югалтмаган зур куллары гомере буе аның хезмәт сөюе турында сөйли.

— Әйе, минем әни эш остасы иде,— дип башлый сүзен рәссам һәм журналист Мансур Рәхимов.— Бик матур итеп аяк киемнәренә бизәкләр төшерә иде. Бизәк-чигешләрнең нинди генә төрләрен белми иде ул! Бәйрәмнәрдә гармунда уйнавына хәйран калмаган кеше булмый иде... Татар халык сәнгатенә, музыкага мәхәббәтем аңардан килә...

Мансур Зыятдинович, ул чор кешеләренә хас булганча, мәктәп тәмамлый, фабрика-завод училищесында мехчылар һөнәрен үзләштерә, шул ук вакытта кичләрен Татарстан Дәүләт музееның сәнгать студиясенә йөри. Ә 1939 елда, Казан художество училищесында укыган вакытта, Армия хезмәтенә алына. Аннары сугыш...

Атаклы Көнчыгыш флоты составында ике сугыш кичергән Рәхимовның, ул елларның хәтере булып, кызылфлотчы дуслары турындагы рәсемнәр галереясе бар. Гади кәгазьгә, гади каләм белән төшерелгән япь-яшь сугышчы егетләрнең бу портретлары тормышчан булулары белән кыйммәт.

Патриотик, сугыш һәм тынычлык темасы Мансур Зыятдинович иҗаты өчен төп темага әверелә. Ватан алдында соңгы чиккә хәтле үз бурычларын үтәгән Муса Җәлил, Абдулла Алиш портретлары, беренче татар большевигы Хөсәен Ямашев, Мулланур Вахитов рәсемнәре, мәсәлән, бүген дә батырлыкка, туган илгә мәдхия булып яңгырый. Яшь партизан, шагыйрь Зәки Нури, яшь курсант, шагыйрь Фәнис Яруллин, сугыш һәм хезмәт ветераны А. Низаметдинов портретлары Рәхимовның иң әйбәт график эшләреннән санала.

Рәссам Казанның завод-фабрика эшчеләре арасында аеруча хөрмәт казанды. Ул алар өчен күргәзмәләр оештырып, сүзе, каләме һәм пумаласы аша яшьләрне Татарстанның үткәне, аның атаклы кешеләре белән таныштырып бара.

Татарстанның өлкән графигы Мансур Зыятдиновичның 1986 елның көзендә, Офицерлар йортында булган күргәзмәсе аеруча игътибарга лаек. Әлеге күргәзмәдә кызылфлотчылар портретлары, сугыштан соңгы еллардагы башка әсәрләр — китап, журнал графикасы да куелды.

Бөек Октябрьнең 70 еллыгы уңаеннан, бүген рәссам «Казанда Октябрь революциясе көннәре»нә багышланган график цикл өстендә эшли.

Без аның бу яңа иҗаты белән очрашуны көтәбез.

М. ИЛЬИНА.



ТАҢ КЫЗЫ



Рәсемдә: Зөһрә Баимбетова. 1920 елның декабрендә төшкән рәсеме.

1921 елның 19 январе. Казан дәүләт университетының Актлар залында татар эшче һәм крестьян хатын-кызларының беренче съезды ачыла. Гомер буе авыр тормыш белән изелгән татар хатын-кызларының 350 вәкиле Татарстан Халык Комиссарлары Советы Председателе Сәхибгәрәй Сәетгалиевнең «Социализм төзүдә татар хатын-кызларының бурычлары» дигән чыгышын тыңлыйлар. Барысының да кулларында бүләкләр, күбесенең күзләрендә яшь бөртекләре. Арада бәлки әле «ирләр белән бертигез хокук», «иҗтимагый-политик һәм дәүләт тормышына актив катнашу» дигән сүзләрне аңлап бетермәүчеләре дә булгандыр, әмма илдәге бөек үзгәрешләрдә күбесе нидер дәрәҗәдә катнашкан, аларны күрә, тоя, йөрәкләре белән кичерә иделәр.

Съездның рәисе, партия өлкә комитетының хатын-кызлар бүлеге мөдире, съездны оештыру көннәрендә ашын да, ялын да оныткан Зөһрә Баимбетованың матур йөзе шатлыктан балкый. Күпме рәхмәт сүзе ишетергә туры килде аңа бүген. «Безне кешегә санап дөньяга чыгардың, изге җаннардандыр син, балакаем, таң кызыдыр син»,— дип сөйделәр аны аркасыннан. Мәшәкатьләр, борчылулар, шикләнүләр онытылды. Съезд 22 январьга кадәр гөрләп барды. Үзәк һәм җирле матбугат съездның эшенә югары бәя бирделәр.

Әйе, Зөһрә Баимбетова татар хатын-кызлары тормышына революция давылын алып кергән беренчеләрнең дә беренчесе булды.

Зөһрә 1899 елда Уфада эшче семьясында дөньяга килә. Үткен, чая, укуга сәләтле бу кызына Әхтәм агай үз заманы өчен тирән белем алырга булыша. Мең газаплар белән казна хисабына ул кызын башта җидееллык русбашкорт училищесында, ә аннан соң педагогик курсларда укыта.

Марксистик әдәбият белән дә Зөһрә курсларда укыганда таныша. Рус һәм ана телендә матур сөйләшүе, үткен фикерләре белән Зөһрә теләсә нинди җыелышларда, хатын-кызлар белән аерым очрашуларда һәркемнең йөрәгенә үтеп керә алган. Сыйнфый көрәшнең иң кызган чорында — 1917 елның февралендә — большевиклар әле партияле дә булмаган яшь укытучыга Уфа өязендә хатын-кызлар арасында аңлату, тәрбия бирү эшен ышанып тапшыралар.

Эшче хатын-кызларны Октябрь революциясенә хәзерләүдә ул партиягә зур ярдәм күрсәтә.

1918 елның язында Зөһрә партия сафларына керә. Шунда ук яшь комму-

ҺӘРВАКЫТ КЕШЕЛӘР АРАСЫНДА

Ул һәрвакыт шат күңелле. Һәрвакыт кешеләргә ярдәм итәргә тырыша. Аның табигате шундый. Ә бит аңа инде 90 яшь тулды.

Мөлаем һәм матур җанлы бу кеше — Дарья Кузовенко. Бөек революция ялкыннары аша узган, яңа тормышның җиңүе өчен хәләл көчен кызганмаган, бәхетле илебезнең нигез ташларын салышкан кеше.

Ул авылда авыр тормышлы крестьян гаиләсендә җиде кызның берсе булып үсә. Ата кешегә җирне бик аз бирәләр. Ул, ачтан үтермәс өчен, гаиләсен Казанга алып килә һәм тегү фабрикасына эшкә урнаша.

Хезмәт юлын Дарья капиталист Шабановларның тегү фабрикасында башлап җибәрә. 1920 елдан аяк киемнәре тегү фабрикасында эшли. (Хәзерге «Спартак» аяк киемнәре тегү берләшмәсе).

Совет власте чорында гына Дарья Кузовенконың фидакарь хезмәте тиешенчә бәяләнә. Хезмәттәшләре аны профсоюз өлкә комитетына сайлыйлар. Беркадәр анда эшләп, тәҗрибә туплаганнан соң, ул профсоюзлар хәрәкәтенең Югары мәктәбендә махсус белем ала. Аннары җәмәгать тукланы сферасында эшләүчеләр профсоюзының өлкә комитеты председателе итеп сайлана. Казан шәһәр Советының берничә чакырылыш депутаты була.

Д. Кузовенко 1927 елда Татарстан эшче һәм крестьян хатын-кызларының I съездында катнаша. Аны эшче һәм крестьян хатын-кызларының Бөтенсоюз съездына делегат итеп җибәрәләр.

Дарья Кузовенко күптән инде ялда. Әмма җәмәгать эшләрен хәзер дә яратып башкара: яшьләрне тәрбияләү эшендә катнаша. Шәһәр советының торак мәсьәләләре буенча комиссиясе члены буларак та, хезмәт ияләренең көнкүреш шартларын яхшырту буенча ярдәм итә. Ул һәрвакыт кешеләр арасында, алар уе, алар гаме белән янып яши.

Рәуф ХӨСНЕТДИНОВ,
Казан шәһәре.

БӘХЕТ

Артист, рәссам, композиторның бәхете нәрсәдә? Бу сорауның җавабы билгеле. Әгәр син халык күңелен яуласаң, тамашачың-тыңлаучың белән бергә гомер кичерсәң, ил язмышында читтә калмасаң, яшең җитеп хөрмәтле ял иткәндә дә әле синең иҗатың халык күңелендә дәвам итсә — менә шул инде ул бәхет. Бу яктан мин үзем бик бәхетлемен. Әле бүген дә мине онытмаган тамашачыларым бар. Әле бүген дә мин алардан бәхет турында кат-кат уйланырга мәҗбүр итә торган хатлар алам. Шундыйларның берсенә тукталасы килә.

«Хөрмәтле Разия апа! Мин 1985 елда «Азат хатын» журналының март санында «Утлы еллар истәлеге» исемле язмагызны укыган идем. Сезнең мәкаләне укыгач, балаларымнан башка беркемгә дә сөйләмәгән күңел дулкыннарым бәреп чыкты. Алар бүгенге көнгә кадәр тынгылык бирмиләр. Сезгә олы рәхмәтләремне әйтеп, күңелемне бушатырга булдым. Чөнки мин үзем дә Сез язганнарның шаһите бит.

нистны Уфа губерна мөселман комиссариатына секретарь итеп җибәрәләр. Бер үк вакытта аңа татар, башкорт хатын-кызлары арасында агитация һәм пропаганда эшен җәелдерергә дә туры килә.

Аның бу эшенә зур бәя биргән Уфа коммунистлары Зөһрәне Советларның V Бөтенроссия съездына делегат итеп сайлыйлар.

Съездда Зөһрә беренче мәртәбә революция юлбашчысы Ленинны тыңлый. Владимир Ильичның өндәве буенча съезд делегатлары барысы да ирекле рәвештә әле яңа гына оешкан Көнчыгыш фронтына китәләр. Зөһрә 5-Армиянең Политбүлегенә җибәрелә. Авыр сугышларда катнашып, ул Уфага әйләнеп кайтканда, 1919 елның июне була.

1919 елның октябрендә Мөселман Хәрби Коллегиясе чакыруы буенча З. Баимбетова Казанга килә. Башта ул Казан губерна комитетының мөселман секциясендә секретарь булып эшли. Мәгълүм булганча, 1919 елның ноябрендә партия комитетлары каршында махсус хатын-кыз бүлекләре оештырыла. Бу бүлекләр хатын-кызларны җәмәгать эшләренә тарту буенча бик зур эш башкаралар. Татар хатын-кызлары арасында шушы эшне җитәкләү Зөһрәгә тапшырыла.

Ул елларда Зөһрә Баимбетовага республикабыз хатын-кызлар хәрәкәтенең үзәгендә торган Н. А. Ванькова, А. П. Шувалова, М. Ф. Ильина, А. Сәйфи, М. Фәйзуллина, Ш. Азанова һәм башка иптәшләр ярдәм итәләр.

Хатын-кызлар арасында җыелышлар, конференцияләр үткәрү; балалар бакчалары, эшсез хатын-кызлар өчен артельләр оештыру; мәктәпләргә, рабфакларга хатын-кызларны кертү; профсоюз, кооператив оешмалары, совет органнары эшенә хатын-кызларны тарту; делегат җыелышлары оештыру һәм аларга көндәлек ярдәм күрсәтү; Кызыл Армиягә ярдәм атналары оештыру — менә шундый һәм башка бик күп төрле вазифаларны үтәргә Зөһрә башлап йөри, башкаларны оештыра.

Ул шул еллар матбугатында чыгып килгән «Хатын-кыз сәхифәләре»нә күп санлы мәкаләләр яза. Аның татар хатын-кызлары хәрәкәте хакындагы язмалары үзәк матбугатта да басыла.

Хатын-кызлар күңелен аңлый белүе, аларның кайгы-хәсрәтләрен үзенеке итеп уртаклашуы, ярдәмчел булганы өчен үз итәләр Казанда Зөһрәне һәм аңа яратып «Таң кызы» диләр.

...1919 елның ноябре. Мәскәүнең «Метрополь» кунакханәсендә Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының II Бөтенроссия съезды бара.

Трибунада — В. И. Ленин. Аның чыгышын йотылып тыңлаган делегатлар арасында берданбер хатын-кыз бар. Ул президиумда секретарь вазифасын башкара.

Тәнәфес вакытында юлбашчыбыз аның янына килә, кемлеген, кайдан килгәнлеген сораша. Зөһрә үзенең Татарстан вәкиле икәнлеген әйтә. Владимир Ильич белән очрашу аның бөтен гомеренә хәтерендә кала.

Баимбетованың эшенә хатын-кызлар хәрәкәтенең дөньякүләм билгеле җитәкчеләре Н. К. Крупская, А. М. Коллонтай зур бәя бирәләр. Ачылышы 1921 елның 21 июненә билгеләнгән Көнчыгыш хатын-кызларының I Бөтенроссия съездына доклад хәзерләү дә нәкъ Зөһрәгә тапшырылуы очраклы хәл түгел, әлбәттә.

Илдә ачлык башлангач, съезд үткәрелмичә кала. Бу вакытта хатын-кызлар бүлеге мөдире Зөһрәгә гаять авыр бурыч йөкләнә. Ул ач балаларга ярдәм күрсәтү комиссиясе председателе, Татарстанда ачларга ярдәм күрсәтү комиссиясе члены, Халык Мәгариф Комиссариатының социаль-тәрбия бүлеге мөдире вазифаларын башкара.

«Гомер буе исемнән чыкмады ул коточкыч көннәр»,— дип яза ул истәлекләрендә. Тимер юл буйларында, вокзалларда, күпер асларында, ташландык, җимерек өйләрдә аунаган тәрбиячесез, ятим балаларны күпме җыйдылар икән Зөһрә һәм аның ярдәмчеләре. Ач балаларны җыеп, беренче ярдәм күрсәтү, поездларга төяп икмәкле өлкәләргә озату үзләре дә рискка туймаган хатын-кызлар өчен җиңел булмагандыр.

Зөһрә Баимбетова Советларның VIII Бөтенроссия съездында, партиянең X съездында Татарстан вәкиле булып катнашты.

Зөһрә Баимбетова соңгы көннәренә кадәр партиянең актив эшчесе булды. Нинди генә эш тапшырылмасын, ул аны намус белән үтәде. Аның гомере балкып янган йолдыз кебек матур, якты булды, ул халык бәхете белән бәхетле булды.

Тәэминә БИКТИМЕРОВА,
тарих фәннәре кандидаты.

ТУРЫНДА УЙЛАНУ

Мин шиле гаиләдә үстем. Сугышның беренче көннәреннән үк диярлек авылларга илебезнең төрле шәһәрләреннән, завод-фабрика эшенә дип, чакыру килә башлады. Миннән зурракларыбыз заводларга эшкә китте. Ә мине 7 нче класста укыганда ФЗОга (фабрично-заводское обучение) Казанга алып киттеләр.

Житен комбинатында һөнәргә өйрәнәбез: 2 сәгать укыйбыз, 8 сәгать эшлибез. Тору урыныбыз Гладилов урамындагы зур бер таш клубта иде. Эштә фронт өчен брезент тукый идек. Станокларга буй җитмәгәч, кечкенә эскәмияләр куйдылар. Шулай итеп, эшләп Җиңү көнен дә җиткердек.

Әйе. 9 нчы Май килде. Иртән иртүк тәрбиячебез Нәгыймә апа безне уятты: «Торыгыз, балалар, сугыш бетте...» — диде ул бик тә дулкынланып. Сикереп торып, караватыбызда сикерешә башладык. Нәгыймә апабыз безгә карап елап тора. Безне сафларга тезеп, бер каенлыкка алып киттеләр (ул парк булгандыр, мөгаен). Анда каенга беркетелгән репродуктордан Левитанны тыңладык. Андагы халык, күз яше, җыр-бию... Яңадан ике гомер яшәсәм дә онытачак түгелмен! Аннан соң безне, шул тезелгән килеш, Бауман урамына алып чыктылар. Урамнарда алма төшәрлек тә урын юк: халык, халык, халык! Шул халыкны аралый-аралый безне (балалар бит!), Разия апа, Сез концерт биргән машина кырыена ук китереп бастырдылар. Машина кузгалган саен, без дә кузгалдык, артыгыздан калмыйча, көнозын йөрдек. Кич арып-талып кайткач кына, бүген без ашамаган бит әле дип, искә төшердек.

Шулай итеп, Сезнең сәнгатегез, Разия апа, Сезнең җырларыгыз минем күңелемә Җиңү белән бергә иңде. Җиңү бәйрәме булып иңде...»

Бу хатны мин тирән дулкынлану белән укыдым. Ул мине сөендерде, нигәдер күзгә яшь тулды. Хәтеремдә бер-бер артлы шатлыклы вакыйгалар яңарды. «Бишьеллыкны 4 елда үтәрбез» дип җырлаган ялкынлы җырлары белән күз алдымнан беренче бишьеллыклар үтте. Менә бик зур тантана белән узган Верховный Советка сайлау көннәре. Иртәнге 6 дан төнге 12 гә хәтле сайлау участокларында концерт бирүләр... Бинийаз зур төзелешләр. БАМ, КамАЗ төзүчеләре алдында чыгышлар... Азмы илебездә булган шундый шатлыклы вакыйгалар?!. Болар бит барысы да сәнгать белән турыдан-туры бәйле. Алар үз чиратында сәнгать әсәрләре тудырдылар, сәнгать исә аларга хезмәт итте, алар белән янәшә атлады.

Инде еллар узгач та, сәнгать өлкәсендә эшләгән эшебезне, җырлаган җырларыбызны халык онытмый икән, бүгенге көнгә хәтле үзләренең олы рәхмәтләрен белдереп торалар икән — артист өчен бу бик зур бәхет инде. Мин дә ерак Дүшәмбе шәһәреннән килгән әлеге хатны укыгач, үз-үземә тагын бер кат: «бәхетлемен» дидем...

Һәм шушы кечкенә генә язмам аркылы, 40-50 ел элек җырлаган җырларымны да онытмыйча, зур хөрмәт белән искә алган тамашачыларыма, мине бәхетле иткән халкыма олы рәхмәтемне белдерәсем килә:

— Рәхмәт сезгә, кадерле дуслар!

Разия ТИМЕРХАНОВА,
Татарстанның атказанган артисткасы.



МӘСКӘҮДӘН

Арча юлыннан Бөрелегә таба борылуга, больница УАЗигы шлагбаум каршында туктап калды. Аннан әле яңа гына поезд узып киткән һәм киртәне күтәрергә өлгермәгәннәр иде, күрәсең. Чагыштырып баксаң, Сәкинә Нургалиевнаның үз халәте дә шушыңа охшаш бит. Кремльнең Зур сараенда шаулап-гөрләп үткән Бөтенсоюз хатын-кызлар конференциясе анда катнашучы 1200 дән артык делегатның һәммәсен, бер мәлгә тукталып, уйланырга мәҗбүр итте. Әйтерсең, ул аларны гаҗәеп бер шлагбаум алдына куйды. Анда — тылсымлы киртә артында ниләр калды соң?

Бөреледә хатын-кызлар советы дүрт ел элек оешты. Аның председателе итеп, туры сүзле, тынгысыз, чая һәм инициативалы булганы өчен, врач С. Н. Терегулованы сайладылар.

— Профсоюз комитетында, мәктәптә, авыл Советында кырыкмаса-кырык комиссия төзелгән. Аларны кабатламас өчен безгә нинди юлны сайларга? — Иң башлап Сәкинә Нургалиевна советның 15 члены алдында менә шушы мәсьәләне күтәрде.

— Минемчә, гаиләдән башласак, ялгышмабыз кебек,— диде моңа каршы авыл Советы председателе Мария Ефримовна Ананьева.— Бу шундый четерекле җир ки, үтеп керсә дә, хатын-кыз сизгерлеге һәм хәйләсе генә үтеп керер.

Балалар бакчасы мөдире Л. М. Смирнова да, уку-укыту эшләре буенча мәктәп директоры урынбасары О. Н. Петрашова, клуб мөдире Н. П. Дәүләтшина да һәм башкалар да әлеге фикерне күтәреп алды. Шулай итеп, гаугалы гаиләләр, авыр үсмерләр, оя кора алмый тинтерәгән буйдаклар, баласына сыймаган карт-коры советның тәрбия зонасына килеп керде.

Ә андыйлар Бөреледә байтак икән. Ник дисәң, совхозда аннан-моннан җыелган халык өстенлек итә. Гаилә корабы җимерелгәннән соң вакытлыча якорь салучылар, гөнаһлары өчен шәһәрдә яшәүдән мәхрүм ителгәннәр дә аз түгел. Шуңа күрә Сәкинә Нургалиевна Бөреле халкын, үзәге тирәнгә китсә дә, ян тамырлары нык өлгермәгән агачка тиңләргә ярата. Кайберәүләрнең әчүдән бизәргә теләмәве, никахларның йомшаклыгы, әхлакның сайлыгы менә шуннан килә, дип саный ул.

Аңа, педиатр буларак, соңгы өч елда гына да ун нәнине балалар йортына урнаштыру белән шөгыльләнергә туры килде. Тере җанны дөньяга китерәләр дә больницада калдырып чыгып китәләр. Яшь-яшь аналар үзләре тереклек биргән нарасыйлардан баш тарта. Авылда күрелгән хәлмени бу? Дөрес, бу аналы ятимнәрнең кайберләренә сирәк-мирәк бәхет елмаеп куя: сау-сәламәтләрен, матурларын читләр балалыкка ала. Врач Терегулова, еракта булса да, аларның язмышы белән кызыксынып тора. Ятимлек ачысын сиздермәслек җылы кулларга, киң күңеллеләргә эләккәннәре өчен куанып яши. Ә гарип, чирле туулары аркасында инвалидлар йортларында гомер кичерергә дучар ителгәннәр өчен врачның йөрәгеннән өзлексез кан саркый. Бу җинаятьнең сәбәбе күз алдында — эчүчелек бит.

Әлбәттә, моңа кадәр дә Бөреледә, эчүчелек белән килешеп, кул кушырып утырмадылар. Авыл Советына чакырту да, төрле комиссияләр тикшерүенә куе да — бары да булды. Эчүчелеккә каршы көрәш турында Указ чыккан артыннан берьюлы 27 эш тикшерелде. Бераз басылган кебек тоелдылар. Ләкин бу күз яздыру гына икән. Чир хәзер йортларга кереп качты. Менә шуннан ничек тә тукмаклап чыгарасы иде аны. Шул теләк көннәрдән бер көнне совет членнарын Мельниковалар өенә алып китте. Бу фатир тутырык хатын-кыз. Әби, әни, аның ике кызы — һәммәсе шешә артыннан җир читенә йөгерергә әзер. Шуңа күрә, күп кызлы йортта суга барырга кеше юк, дигән кебегрәк килеп чыга. Фатир түшәменә кадәр пычракка баткан. Авылның абруйлы биш-алты хатыны, чакырылмаган кунак булып, өйләренә килер, дип башларына да кермәгән аларның. Оятлары качып бетмәгән икән әле. Берсен-берсе уздырып:

— Ремонт ясарга йөри идек,— дип акланырга тотындылар. Икенче тикшерүдә, чынлап та, түшәм штукатурланган, тәрәзәләр буяп ябыштырылган иде инде.

Ләкин боларны һич күздән яздырырга ярамый. Һаман тикшерү белән йөрсәң, ул аларны ярсытачак кына. Уйлана торгач, күзәтчелекне... балалар аша дәвам итәргә килештеләр. Бу гаиләдән мәктәптә ике бала укый. Балалар — гаиләнең көзгесе ич. Аларга кара да өйдәге хәлне төзәтү өчен тиешле «дару»ны куллана тор. Авыр үсмерләр белән эшләү комиссиясе председателе О. Н. Петрашова моның остасына әйләнеп бара. Әгәр шул тавышгауга әчендә үсеп, Алеша Мельников, бернинди «ЧП»ларсыз тугызынчы класска кадәр җиткән икән, моның серен Ольга Николаевнаның педагогик осталыгыннан һәм үсмернең яраткан электротехника түгәрәге җитәкчесе Р. Г. Терегуловның шифалы йогынтысыннан эзләргә кирәк.

Фикерләп карасаң, тәрбия эше — врач эше кебек үк. Фоноскоп аша тыңлап, диагноз кую белән генә чикләнә алмыйсың, дәваларга кирәк. Кайсын — үлән, кайсын — «укол», ә кайсын... «пычак» белән. Менә Бөреледә тагын бер гаилә бар.— Бутырскийлар. Кызларына — 3, малайларына 7 яшь. Ата әле күптән түгел генә кеше үз теләге белән аяк та атламый торган ерак җирләрдән йөреп кайтты. Ә ана кеше Казанга эшкә барып йөри. Балалар иртәдән кичкә кадәр япа-ялгыз. Хатын-кызлар советы бу гаиләгә дә килеп кагылмыйча булдыра алмады. Ана алдына:

— Я — эшең, я — балаларың,— дигән катгый таләп куярга туры килде. Бутырская балаларын сайлады. Вакытында ясалган авырттыргыч «укол» бу гаиләдә шайтан таягы үсеп китәргә җай бирмәс, дигән өмет уята.

Кадыйровлар гаиләсенә дә вакытында шундый чара күрә алган булсалар! Бәлкем, эш Розаны ана хокукларыннан мәхрүм итү кебек күп кан һәм күз яше түктергән «операция»гә барып җитмәгән булыр иде. Биш балалы бу хатынның Сәкинә Нургалиевна белә белгәннән бирле аек көне, гаиләдә гаме булмады. Кайсы яктан гына карасаң да, ана исемен йөртергә хокуксыз сыман. Ләкин шушы көнгә кадәр С. Н. Терегулованың күңеленнән икеләнү китми. Ятимлек иң начар анадан да начаррак түгелме соң? Роза үзе шәһәргә киткәннән бирле кайтып балаларының күзенә күренгәне юк. Ә менә профтехучилищеда укучы кызы аны эзләп тапкан. Әнисе белән яшисе килә аның. Мәктәптә укучы кызының да йөзендә — сагыну сагышлары. Сумкасын гына өенә чыгарып куя да кабат мәктәпкә кереп җитә. Гел



КАЙТКАЧ

озайтылган көн группасы тәрбиячеләренә булышып, алар янында сырпаланып йөри. Дөрес, мәктәп аңа да, бу гаиләнең башка балаларына да киемсалымын ала, бушлай ашата, укытучылар җай чыккан саен иркәләп, назлап алырга тырышалар. Тик боларның берсе дә ана бирергә тиешле җылылыкны алмаштыра алмый, күрәсең.

Шуны күреп, тоеп торган хатын-кызлар советы членнары хәзер, алдан килешенгәндәй, нинди генә гаилә булса да, аны җимерми калуны алга сөрәләр. Ике ел элек суд Люда Чапуринаның да яңа туган улын үзеннән алып, әби-бабасына тәрбиягә биргән иде. Сәкинә Нургалиевна бу яшь хатынны больницага эшкә чакырды. Анасы кебек, адым саен киңәшен биреп, кайгыртып тора. Үзгәрә кеше. Моны авылдашлары да сизеп алган инде. Күптән түгел генә Мария Ефримовна аны авыл Советына чакыртып:

— Люда, эшләрең шулай барса, улыңны кабат үз яныңа кайтара аласың. Әтисе белән никах нығытырга иде сезгә...— дип күңеленә уй салган.

Шушындый хәлләр белән очрашып торган совет соңгы вакытта аны булдырмау чараларын күрергә омтыла. Үткән язда үрнәк йорт-җир конкурсы игълан иттеләр. Күпләр каралты-курасын җыйнаклау, бизәү белән мавыгып китте. Өйләренең эче-тышы гына түгел, яшәү рәвешләре дә һәркемгә үрнәк булырлык шофер Халиков белән тимерче Хисмәтуллин гаиләләре бу гаҗәеп ярышта һәммәсенең борынына чиертте. Ә соңыннан җиңүчеләр үзләре үк аларга тиешле приз акчасына чәчәк орлыклары сатып алып, бөтен авыл халкына таратырга тәкъдим иттеләр.

Халык күңелен кузгатуның мең әмәле бар. Ул бер кымшанса, төнбоек кебек ачылып китә. Яңа ел алдыннан клуб мөдире Наталья Петровна Дәүләтшина «Кичәгә өлкәннәр генә чакырыла. Программада элекке биюләр, җырлар, уеннар» дигән белдерү элгәч, анда күп кеше җыелыр дип, берсе дә ышанмаган иде. Килү генә түгел, хәлдән тайганчы вальс, краковяк, танго биеделәр, тамаклары карлыкканчы халык җырларын, романслар җырладылар. Хәтта яшьләр кызыгырлык булды.

Бу уңыш икенчесенә рухландырды. «Яше утыздан үткәннәр өчен...» дигән кичә шулай туды. Беренче коймак төерле чыкса да, Наталья Петровнаның бирешергә исәбе юк. Гомумән, бу клуб мөдире — Бөреле өчен чын табыш. Җырлый, бии генә түгел, скрипкада да уйный. Клубта һәм мәктәптә бәйләү, макраме үрү түгәрәкләре оештырып җибәрде. Хәзер ун-унике яшьлек кызлардан алып әбиләргә кадәр һәркемнең кулында энә-җеп. Ә бер көнне клуб мөдире йөгереп С. Н. Терегулова янына — больницага менгән.

— Сәкинә Нургалиевна, механика цехы егетләрен Совет Армиясе көненә концерт куярга кыстасам, җиңәрмен микән? — ди. — Бигрәк мүкләнгән җаннар җыелган бит анда.

Киңәшләшүләре Сәкинә Нургалиевна Мәскәүгә китәр алдыннан булган иде. Ул кайтуга килешенеп, программасын төзеп куйганнар. Наталья бу чаялыгы белән җиде башлы аждаһаның йөрәгенә дә юл табар. Аны рухландырып торырга гына кирәк. Ә Сәкинә Нургалиевна ул рухны Мәскәүдән һәммәсенә җитәрлек итеп алып кайтты.

...Нарат урманы уртасында утырган Бөрелесенә кайтып кергәч тә, аның беренче эше хатын-кызлар советы членнарына хәбәр салу булды: иртәгә чираттан тыш утырышка җыелабыз.

Аннары, Венгриядә хезмәт итүче улы Иректән килгән сагыну хатын укып чыкты да, ире Айрат белән кызы Лилиягә Мәскәүдә күргән-белгәннәрен сөйләргә утырды. Ул гаҗәпләнеп, тәэсирләнеп сөйләргә һәм шуның белән тыңлаучыларны җилкендереп җибәрергә ярата. Бу юлы да сүзе үзе туып-үскән Әгерҗе якларындагы Иж суы кебек ярларына кагып-кагып акты. Башкалада узган өч көндә берәүнең гомеренә җитәрлек вакыйгалар кичергән иде ул. Кремльнең Зур сараенда очрашу-танышулар, «Крестьянка» журналында кунакта булу, Социалистик Хезмәт Герое, Арча укытучысы Стелла Зәкиевна Габдрахманова белән дуслашып кайту хакында, конференциядә кузгатылган проблемалар турында сөйләшү өчен Шаһзадәнең мең дә бер кичәсе дә җитмәс кебек иде. Ригадан, Минскидан, Тбилисидан адреслар алышкан дусларының һәрберсенең дә үз авыруы, авырткан урыны бар. Грузия вәкиле, мәсәлән, хатын-кызлар советының безнең республикада беренче бурычы — наркомания белән көрәшү, дип белдерде. Литвада никах таркалуны киметү чараларын эзлиләр икән. Белоруссиялеләрнең кайгысында яшь буынны телевизион тапшырулар аша Көнбатыштан сарыккан әхлаксызлыктан саклап калу... Болар фонында Сәкинә Нургалиевнага үзләренең кайгы-хәсрәте кечкенәрәк сыман тоелган иде. Кайтып, кочегар Гыйлаҗевның ике игезәге алдында хатынын тотып кыйнаганын ишеткәч, тагын үпкәсе күперде. Хатын-кызлар советына советча яшәү рәвешен тапларлык мондый күренеш белән килешеп яшәү һич ярамый. Шуңа күрә иртәгесен, авыл Советында чираттан тыш утырышка җыелгач, ул үзәккә шул фикерне куйды да:

— Хатын-кызларның Бөтенсоюз комитеты турындагы Устав безнең советка зур хокуклар бирә. Партия безне тәрбия эшендә үзенең ярдәмчесе итеп күрә,— диде ул, иң көчле тәэсирләре белән уртаклашканнан соң.— Шуңа күрә бүгеннән яңача эшли башласак иде. Күбрәк — кешеләр арасында булырга, аларны тыңларга, аларга таянырга...

Сәкинә Нургалиевна үзе атна-ун көн эчендә балалар бакчасын, мәктәпне, җәнлек фермасын йөреп чыкты. Хатын-кызларның гозерләре, теләк һәм таләпләре аның өстенә печән кибәне кебек ишелеп төште. Арада иң четереклесе җәнлек караучыларны кул хезмәтеннән коткару турындагысы булды. Моннан сигез ел элек Бөреледә участок больницасын ябу турында сүз таралгач, җәнлекчеләр аңа шундый ук олы гозер белән килеп егылганнар иде: яңа бина салуны зинһар, туктатмасыннар иде! Ул чакта заман башка иде. Якын-тирәдә яклау тапмагач, гомере буе Әгерҗе белән Казаннан ары китмәгән С. Н. Терегулова тәвәккәлләде дә Мәскәүгә китте. Ул кайтканнан соң бер ай үттеме, юкмы — ашыгып-ашыгып больница бинасын төзи башладылар. Авылның иң калку урынында, урманга сыенып утырган ап-ак больница шәһәрчеге — бүгенге көндә Бөреленең яме һәм мактанычы. Җәнлекчеләрнең яңа гозере дә бер тормышка ашмыйча калмас. Чөнки хәзер тәвәккәлләп йөрүче — берәү генә түгел, күп кешеле совет. Үз Уставы һәм программасы булган хатын-кызлар советы.

Илсөяр ХӘЙРУЛЛИНА

ХЕЗМӘТТӘ ЯУЛАНГАН ХӨРМӘТ

Смена башланырга бер сәгатьләп вакыт булса да, Фәния апа эшкә ашыкты. Гадәттәгечә, җәяүләп китте ул фабрикага. «Арыйсыздыр, болай йөреп»,— диючеләр дә күп аңа. Фәния апа аларга һәрвакыт елмаеп: «Җәяү йөрү — гомергә яшь булып калу дигән сүз ул»,— дип җавап бирә.

Бүген Фәния апаның уйлары эш хакында гына түгел иде. Әйе, тиздән кызы Даниянең туе булачак бит. Күпме мәшәкать төшә әни кешегә андый вакытта. Кызы да, булачак кияве Рамил дә: «Борчылмагыз бер дә, барысын да үзебез карарбыз»,— дисәләр дә, балалар бит, барыбер нәрсәне булса да онытырлар кебек тоела иде Фәния апага.

Шулай уйга чумып, цехка килеп җиткәнен сизми дә калды ул. Беренче булып аңа Миңлегали Шәмсевәлиев очрады.

— Чын күңелемнән котлыйм, Фәния апа! — дип каршылады ул.

«Иртәрәк түгелме соң, туй булмады бит әле»,— дип уйлап алды Фәния апа.

Ә Миңлегали котлавын дәвам иттерде:

— Ленин ордены белән бүләкләгәннәр сезне, газетадан үзем укыдым,— диде.

«Котлыйбыз, Фәния апа!» — «Сезнең өчен бик шатбыз»,— дип урап алдылар кызлар да. Котлаулар смена ахырынача тынмады.

Шатлык булса да, кайгы килсә дә, иң элек Фәния апаның күзләренә яшь бәреп чыга. Я җәйге яңгыр сыман җылы булалар күз яшьләре, я әче, авыр булалар. Я менә бүгенге кебек, үзенең яраткан «Су буе»н җырлагандагыча, күңеле җиңеләеп китә.

Башкача да була: йөрәк кинәт кысылып, әрнеп куя. Балачагын, әнисен, авыр сугыш елларын искә төшергәндә шулай була. Арча районының Сеҗе авылын ачык күз алдына китерә Фәния апа. Әнисе, Фәрихә Гыйззәтуллина, авылдашлары белән бергә оборона эшләренә йөрде. Әнисе тәмам арып кайтып керә, баскан җирендә күзләре йомыла. Тик шулай да, кызына ягымлы сүзләр таба, әкият сөйли, аннан соң, бишек җыры көйли-көйли, кызы белән бергә йокыга тала. Иртүк торып, кибеп тә җитмәгән бишмәтен яңадан киеп, тагын эшкә чыгып китә. Тик бервакытта да балалары аның тормыштан зарлануын ишетмәделәр. Күпме тырышлык, сабырлык булган ана йөрәгендә! Колхозда да, Казанга күчкәч тә җиңел эш эзләмәде ул. Казанның 1 нче номерлы кер юу йортында эшләгәндә стахановчы булды. Балаларына гел: «Эшләгән, яшәгән җирегездә өлкәннәрне хөрмәтләсәгез, алардан өйрәнсәгез, беркайчан да йөзегезгә кызыллык килмәс»,— дия торган иде.

Әнисенең бу сүзләре Фәниянең күңеленә гомергә кереп калды. Утыз ел элек «Спартак» аяк киемнәре тегү берләшмәсенә килде ул. Өйдә киелә торган җиңел аяк киемнәре тегәргә өйрәнде. Бик булдыклы булып чыкты Фәния Сәләхова. Бу эш аңа артык җиңел кебек тоела башлады. һәм ул үзе теләп тире итек (унты) тегү цехына күчте. Тегү серләрен җентекләп өйрәнде кыз һәм берләшмәдә иң авырлардан саналган тире итек тегү операциясен тиз үзләштерде. Шул ук вакытта кичке мәктәптә дә укыды. Остазы Мария Сергеева мактап туя алмады Фәнияне. Цех начальнигы А. Ягуткин да аны үзләренә эшкә алганына шатланды. Остазы башка җиргә күчкәч, Фәния Сәләхова аның урынына иң катлаулы операциягә — рант беркетүгә басты. Бүген Фәния апа әлеге эшнең иң зур остасы.

1975 елда Фәния апа III Дәрәҗә Хезмәт Даны ордены белән бүләкләнде. Ә ике елдан соң «Почет билгесе» орденына лаек булды.

Коллективка, хезмәттәшләренә Фәния апа һәрчак игътибарлы, ярдәмчел, ихтирамлы. Ул берничә ел торак-көнкүреш ко-





Р. МӨХӘММӘТҖАНОВ фотолары.



ИГЕНЧЕНЕҢ



Рәсемдә Ф. Н. Сәләхова. В. Зотов фотосы.

миссиясе, иптәшләр суды члены, алдынгы эш алымнарын өйрәтү мәктәбенең җитәкчесе булды. Утызлап шәкерте арасыннан кайберләре үзләре үк остазлар хәзер. Фәния ападан өйрәнеп, соңыннан берләшмә алдынгысы булган хезмәт ветераны Т. Малышева моннан бер-ике ел элек ялга чыкты. Гаҗәпләнер урын юк, чөнки яхшы остадан яше дә, карты да өйрәнә.

Фәния апа яшь эшчеләр Зөлфия Фәтхуллина белән Руфия Фалихованы да олы хезмәт юлына чыгарды. Данлыклы останың горурлыгы алар, чөнки Фәния апа үзенең төп операциясен беренче тапкыр яшьләргә өйрәтте. Бу эшне иң элек тоярга, сиземләргә кирәк, дип саный остаз. Кызларны да кисәтеп куйды: «Мин таләпчән кешемен, кызлар, орышкан чакларым да булыр...» — диде. Зөлфия белән Руфиянең бу катлаулы эшнең нечкәлекләрен төшенә алуларына шикләнеп тә куйган иде. Ә кызлар зиһенле дә, тырыш та булып чыктылар, эшкә бер тотынгач, кире чигенмәделәр. Шулай да, остазлары янына, хәзер дә йөгереп килеп, аңлашылмаганны сорыйлар. Фәния апа үзе дә аларның уңышлары белән гел кызыксынып тора.

Хөкүмәт бүләкләре тапшырыласы тантаналы җыелышны Фәния апа дулкынланып көтте. Үзе гел уйланып йөрде: Ленин орденына лаек булырлык ниләр эшләде соң әле ул?

Мастер Әминә Гарифова сменага иртәрәк килүне яисә эштән соң берәр сәгатькә калуны сорап сүз кушса, Фәния апа һәрчак риза булды. Тик башка хезмәттәшләре дә шундый бит. Фәния апа теләсә нинди операцияне башкара ала. Монысын да күпләр булдыра.

Дөрес анысы, слесарьларны исәпкә алмаганда, аңардан башка берәү дә тарттыру каешларын кайый торган машинаны көйли белми. «Бик көйсез машина, күптән алыштырасы иде»,— диләр цехта. Тик әлегә яңасы юк, шуңа күрә шул машинаның җаен таба белергә кирәк. Тик монда да Фәния апа ис китәрлек нәрсә күрми. Подряд ысулы белән эшләгәч, нәкъ шулай булырга тиеш. Һәркем өчен ахыргы нәтиҗә мөһим.

Бәрәүләрнең начар сыйфатлы эше яки тәртипсезлеге яныннан тыныч кына узып китү гадәте дә юк бу коллективта. Берберсен аңлап, яратып, эшлиләр. Хәзер дә яхшы сүзләр, матур теләкләр ничаклы булды. Яшьләр Фәния Нигъмәтовнага багышлап «Яшен» дә чыгарып элгәннәр. Чынлап та уртак сөенечкә әйләнде бу вакыйга.

Кызының туенда да ике шатлык бергә кушылды: яңа семья туу да, эшче хатынның хезмәт бәйрәме дә. Дания дә үзенә тормыш биргән иң кадерле кешесе — әнисе өчен зур горурлык хисе кичерде. Моннан да зуррак түй бүләге буламы соң?! Әфганстанда хезмәт итеп кайткан Рамил да бу олы бүләкнең мәгънәсен яхшы аңлый. Кайда гына бирелмәсен, ул — батырлык, фидакарь хезмәт, Ватан кушкан бурычны үтәргә һәрчак әзер булу.

...Өч кызыл тартмачык тора өстәлдә. III Дәрәҗә Хезмәт Даны ордены, «Почет билгесе» һәм Ленин ордены — Сәләховлар семьясының иң кадерле ядкаре. Мондый ядкарь буыннан-буынга күчә. «Спартак» аяк киемнәре тегү берләшмәсенең данлыклы эшчесе Фәния Нигъмәтовна Сәләхованың орденнары да балаларын, шәкертләрен, хезмәттәшләрен яңа хезмәт биеклекләренә әйди.

З. БАДЫЙКШАНОВА.



ИРКЕН ҖЫРЫ СЫМАН

Сәйдә ЗЫЯТДИНОВА

Игенченең җан җылысы ахры,
Газиз җирне шулай җылыта —
Җылыт, язкай!
Син дә җылыт җирне
Бер көне дә язның ел тота.

Җирдә икмәк исе!
И, табигать!
Бир син кояшлысын яңгырның!
Сеңсен сабакларга, башакларга
Офыклардан балкып таң нуры!

Җылыта ла икән газиз җирне
Игенченең йөрәк җылысы —
Игенченең иркен җыры сыман
Чиксез кырда иген сулышы...



СИҢА КАЙТТЫМ, ГҮЗӘЛ ТУГАН ҖИРЕМ

Илгиз ЗАКИРОВ музыкасы

Нәҗип МАДЬЯРОВ сүзләре

Сиңа кайттым, газиз туган җирем,
Сагындырды чишмә буйларың.
Аерылып гомер кичерсәм дә,
Айрылмады синнән уйларым.
Сиңа кайттым, гүзәл туган җирем,
Кырларыңа күңелем җилкенде.
Нурга чумган җәйге үзәннәрең
Бигрәк ямьле, бигрәк сөйкемле.
Сиңа кайттым, газиз туган җирем,
Синдә генә күңелем дәвасы.
Гомеремә якты дәвам өсти
Тугайларның рәхәт һавасы.
Сиңа кайттым, гүзәл туган җирем,
Инешләрең буйлап узарга.
Җанга якын агым суларыңның
Авазына кушылып җырларга.
Сиңа кайттым, газиз туган җирем,
Чынга ашты изге хыялым.
Чит җирләрдә яшәсәм дә, синнән
Айрылмады гомер юлларым.
Сиңа кайттым, гүзәл туган җирем,
Каршылады алсу таңнарың.
Гомеремнең иң шат минутлары
Синдә икәнлеген аңладым.

Аналар

Кави ЛАТЫЙП

Ир уртасындагылар да
аналарга таяна.
Килми сынасылары.
Алар булгач
җиңелрәк дөньялар
сынавы,
иркенрәк сулавы.
Алар белән тәмлерәк
дәрья сулары.

Алтмыш яшьлек
ир-егетләр
аналарга балалар.
Моны тоя Җир-Әнкә,
моны тоя далалар.

Аналар догасы белән
кабына күк йолдызлар,
салыналар калалар.
Чал аналардан
балалар
сүнмәс яшьлек табалар,
үлмәс яшәү табалар.

Аналар — кояшлы һавалар,
колачлы дәрьялар.
Аналар —
күңел яраларына
шифалар-дәвалар.

●

Каләмдәш дустыма

Җиһанда сагыш-моң...
Кабатланмас җәүһәр —
әниеңне югалту белән уртаклашамын.
Кешеләр йөрмәс,
күрмәс карурманга качамын.

Әллә инде шашамын?..
Күңелләрдә яши әниләр.
Алар ерак галәмнәрдән
вәгазьләр сөйләр,
көйләр көйләр.

Түзү кирәк,
үзеңне көчле итеп сизү кирәк,
сүнмәсен дисәң күңел кояшы.
Коткарсын бәлаләрдән
әниеңнең үлемсез догасы.

Шулай гына яшәп буласы,
аналарга һәйкәл куясы,
куясы,
салкын мәрмәр ташларда
кайнар сулышларын тоясы...

●

Хатлар аша сөйләшәмен,
киңәшәмен,
серләшәмен
кырык бер ел әнием белән.

Әрнүләргә,
сызлануларга
кырык бер ел түзелгән.
Түзәр идемме
әнием булмаса?!

Күрәмен аның кемлеген
ерак еллар аша.
Ул миңа бүген дә
яшәү серләрен ача.
Җир-Әнкәнең
күзе,
йөзе,
Үзе булып
каршыма килеп баса
Әнием мәңгелек хәзинә
ләбаса.





МОДАЛАР

И. РОДИОНОВА эшеъ





Тегү мәктәбе,

дүртенче дәрес

БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР КИЕП КАРАУ

Тегелә торган киемегезне алдагы дәресләрдә әйтелгәнчә кисеп, типчеп чыксагыз да, беренче тапкыр киеп караганда барыбер кимчелекләр күрерсез. Бер дә хафаланмагыз — иң оста тегүчеләрдә дә була андый хәл. Тик алар хаталарын оста итеп төзәтә дә беләләр. Әйдәгез, без дә моңа өйрәник.

Менә типчегәннән соң күлмәкне кидегез. Кайбер урыннар җыерылып тора яисә итәге тигез түгел, ди. Борчылмагыз, беренче тапкыр киеп караганда бу табигый. Ә җитешсезлекләрне иң элек дөрес күрә белергә кирәк.

Тегү кагыйдәләре кушуынча, киемне тегелеп беткәч ничек кияргә уйлыйсыз — шулай киеп карагыз (итәк кофта белән, жилет-кофта өстеннән, һ. б.).

Киемнең килешлелеге өске өлешнең ничек утыруыннан тора. Шуңа күрә, анда була торган кимчелекләрне карап чыгу бик мөһим.

Арка өлешеннән башлыйбыз. Тукыма кирәкмәгән урыннарда җыерылып тора. Тегәргә өйрәнә генә башлаучыларга көзге каршында үзләре генә киеп карап, кимчелекләрне күрү, әлбәттә, авыррак. Шуңа күрә, беренче очракларда үзегезнең тегә белүче берәр танышыгыздан ярдәм сорау урынлы булачак. Ул, киемегезнең арка өлешен яхшылап карап, уң ягына төзәтмәләр кертеп билгеләп чыксын.

Беренче тапкыр киеп караганда, гадәттә мондый кимчелекләр була:

1. Арка өлешенең үзегезнең арка озынлыгына туры килүен тикшерегез. Моның өчен билгә нечкә тасма бәйләп кую яхшы. Әгәр бил җөе өстә яки аста булса, җөйне сүтеп, янадан




җөй урыны билгеләгез (1 рәсем).

2. Арка ягында горизонталь җыерчыклар (бил өзек булмаганда) барлыкка килгән. Арка өлешен бераз кыскартып, артык тукыманы җилкә һәм муен уемының арка ягы җөйләренә кертергә кирәк (2 рәсем).




3. Муен уемы тирәсендә тукыма җыерылып тора. Җилкә җөенең алгы ягындагы һәм муен уемының өске өлешендәге җөйләрне сүтеп, алтактаны аскарак төшерәләр (3 рәсем). Тукыма җилкә сызыгының муен уемына якын торган җирендә җыерылса да, шулай эшлиләр (4 рәсем). Әгәр мондый кимчелек арка өлешендә булса, җилкә җөен сүтеп, арттактаны бераз аска төшерегез.





4. Әгәр тукыма җыерчыклары җиң астында күренсә, димәк, җиң уемы кечкенә булган. Төзәтү өчен, уемда 1 см тирәнлектәге бернičә кисем ясап, җөй урынын яңадан билгелиләр (5 рәсем). Әгәр,



киресенчә, уем зур булса, җилкә җөен сүтеп, артык өлешне шунда җыеп куялар. Бу очракта җилкә җөенең дөрес урнашуын игътибар белән карап чыгыгыз (6 рәсем).



5. Күкрәк вытачкасы өстәрәк яки астарак, бик тирән яисә сайрак салынган. Ян җөйне һәм вытачканы сүтегез дә, яңадан ясап, булавкалар белән беркетеп куегыз (7 рәсем).




6. Киемегез таррак булса, ян җөйләрне сүтеп, яңадан үлчәп, җөй сызыгын кабат билгеләгез. Һәм шулай ук булавкалар белән беркетеп куегыз.

7. Беренче тапкыр киеп караганда, җиңнең киңлеген дә, озынлыгы да тикшерелә. Гадәттә, уң җиң алына. Җиң әйләнәсе җиң уемыннан озынрак була, шуңа күрә, җиң әйләнәсе буйлап җеп үткәреп, җыебрак куйсагыз, үзегезгә җайлы булыр.

Каеп тегелә торган җиңне утырту — четерекле эш. Монда тукыманың буй һәм аркылы җепләре кисешкән урынны билгеләп кую бик мөһим.

Җиңне әйләнә буенча тискәре яктан типчиләр (8 рәсем).



Өлге журналдан кисеп алынган булса, иң элек игътибар белән карап чыгыгыз: анда җиңне беркетү өчен махсус нокталар билгеләнгән булуы мөмкин. Һәм җиң уемга иң элек шул нокталарда беркетелә. Әгәр дә андый билгеләр булмаса, җиңнең урта җөен киемнең ян җөенә туры килерлек итеп тегәләр. Моның өчен иң элек җиңнең аскы өлешен беркетәләр. Аннан соң гына тукыманы тиешенчә тигез итеп җыеп, җиңнең өске өлешендәге тамганы да искә алып, өске ягын беркетегез. Бөрмәләр, гадәттә, җиңнең өске өлешендә ясалалар. Җиң әйләнәсе тиеш озынлыкта булмаса, җиңдә аркылы җыерчыклар хасил булачак. Җиңне инсәләр куеп тегәргә уйлыйсыз икән, инсәләр беренче тапкыр киеп

караганда ук әзер һәм беркетелеп куелган булсын.

Җиң кул хәрәкәтләрен чикләмәсен өчен, киңлеген яхшылап үлчәп чыгыгыз. Ә җиң, терсәкне бераз бөккәч, беләзек сөяге капланырлык озынлыкта булырга тиеш.

8. Хәзергә икенче бер тукымадан гына киселгән яка, манжет, кисәләрне дә киемгә беркетеп куегыз һәм аларның урыннарын, формаларын һәм үлчәмнәрен төгәл билгеләгез. Шуннан соң гына аларны киемнең үз тукымасыннан кисеп алырга мөмкин.

Яка дөрес утырсын өчен, муен уемы формасы төгәл киселгән һәм типчелгән булырга тиеш. Яка деталенең уртасы арка өлешенең уртасына туры килсен.

9. Әгәр күлмәгегезнең итәге арттан озынрак яисә җыерылып тора икән, бу вакытта итәкне бил җөенә кирәк кадәр күтәрергә кирәк.

Менә кимчелекләрне төзәттегез дә. Күргәнегезчә, моның өчен түземлелек, зур теләк һәм иренмичә ипләп-җайлап берничә тапкыр сүтеп-тегеп эшләү кирәк.

Киеп карап, төзәтмәләр ясаганнан соң, киемне саклык белән генә салыгыз, булавкаларын төшермәскә тырышыгыз. Салгач, төзәтмәләрне акбур белән сызып чыгыгыз. Дөрес булмаган җөйләрне сүтеп, дөресләп яңадан билгеләгез. Әгәр төзәтмәләр детальләрнең бер яртысында гына булса, аларны икенче яртысына да күчереп куярга онытмагыз. Хәзер инде төзәтмәләрне искә алып, типчеп, тагын бер киеп карагыз. Соңгы төзәтмәләрне кертеп, инде машина белән тегә башларга да ярый. Тик башта, тукыманың җепләре чыгып тормасын өчен, детальләрнең читләрен эшкәртеп, читләп чыгарга кирәк.

Күлмәк теккәндә, башта өске өлеш һәм итәк аерым-аерым тегелә, аннан соң бер-берсенә беркетелә.

Фасоны артык катлаулы булмаган күлмәк мондый тәртиптә тегелә (9 рәсем).

1. Вытачка һәм складлар тегелә. Типчегән җепләр сүтеп алына, вытачкалар детальнең уртасына таба үтүкләнеп куела.

2. Җилкә җөйләре тегелә. Тукыманың калынлыгына карап, җөйләр арка ягына яки ике якка да үтүкләнә.

3. Ян җөйләр тегелә һәм үтүкләнә.

4. Муен уемын тегеп, яканы утырталар.

5. Җиң вытачкалары һәм кисемнәре тегелә.

6. Җиң җөйләре тегелә һәм төймә тишекләре ясала.

7. Җиңнәр утыртыла. Ә җөйләре җиң ягына үтүкләнә.


8. Итәк өлешләре берберсенә тегелә. Җөйләр ике якка үтүкләнә.

9. Итәкне өске өлешкә тоташтыралар.

10. Молния һәм каптырмалар тегелә.


11. Итәкнең аскы өлеше, бөгеп, тигез итеп тегеп куела һәм бик яхшылап үтүкләнә.

Типчегән җепләр ипләп сүтеп алына һәм күлмәк үтүкләнә. Киләсе дәресләрдә бу эшләрнең һәрберсе турында аерым-аерым сөйләнер.



9

БАЛА БЕЛӘН БЕРГӘЛӘП

















Бу күнегүләрне әни кеше кызы яисә улы белән бергәләп башкара ала. Күңелле дә, файдалы да.

ЧЫГАРЫЛЫШ КИЧӘЛӘРЕНӘ

Чыгарылыш кичәләренә мондый күлмәкләрне ефәк яисә киҗе-мамык тукымадан, маркизеттан тегәргә тәкъдим итәбез. Ясалма чәчәк, яки чигеш, яки башка төр тукымадан куелган киң балаитәк аларны бик матур итәчәк. Күлмәкнең җирлеге яки бизәге актан булса, балаитәкләрне ак тукымадан куялар.



А. ХӘСӘНОВА рәсеме

Һәвәскәр бакчачыга

Июнь



Июнь — җәйнең беренче ае. 22 июнь елның иң озын көне, ә төне — иң кыска төн. Бу ай башында кура җиләге, балан, гөлҗимеш куаклары чәчәк ата. Җимеш бирә торган агачлардагы җимешләр зурая башлый.

Әлеге айның уннарына кадәр кыраулар булуы ихтимал, шунлыктан аңа каршы көрәш чарасына әзер булып торырга кирәк.

Июнь аенда җиләк-җимеш һәм чәчәк үсентеләре бик тиз үсә. Җимеш бирә торган агачларда киләсе ел уңышы өчен бөреләр барлыкка килә башлый. Шуңа күрә үсемлек иркенләп үссен өчен бөтен шартлар тудырылырга тиеш. Ябалдашларны зарарлы бөҗәкләрдән саклау зарур. Моның өчен туфракны һәрчак йомшартып-күпертеп, куак һәм агач тирәсен чүп үләннәреннән арындырып торалар.

Чүп үләннәрен чәчәк атып, орлык биргәнче утыйлар, әлбәттә, аларны тамыры белән йолкып алу хәерле.

Бакча каен җиләге «мыек»ларының көзен яңадан утырту өчен кирәкләрен генә калдырып, калганнарын юк итәргә киңәш ителә. Ярала башлаган җиләкләр пычранмасын һәм черемәсен өчен җиргә салам, тал чыбыклары, катыргы, такта кисәкләре куялар, җиләкләрне таякчыкка җеп белән бәйләп куярга да була. Коры елларны җиләк түтәленә су сибәләр.

Чәчәк коюга җимеш агачлары төбенә ныклап су сибәләр һәм тирес белән ашлыйлар. Июнь аенда җимеш бирә торган агачлардагы зарарлы бөҗәк ояларын карап, юк итеп торалар.

Айның икенче яртысында кара карлыган һәм крыжовник җимешләрендә зарарлы бөҗәкләр оялары күренгәли. Андый җимешләрне кайнар сулы савытка җыялар.

Төрле зарарлы бөҗәкләргә каршы халыкта төнәтмәләр һәм саркындылар файдаланыла. Аның өчен әрем, помидор сабагы, кузаклы кызыл борыч, суган кабыгы, горчица, керән тамыры файдаланыла.

Илдар ЮЗЕЕВ

ГАШЫЙКЛАР ТАВЫ

ПОВЕСТЬ-ПОЭМА

Элекке дәверләрдә Гашыйклар тавында түгәрәк тирән күл булган, диләр. Туган җирләрен сагынып, тезелешеп, язларын киек кошлар кайтканнар. Көннәрдән бер көнне шул якның сунарчысы, һәни балалары белән күлдә йөзеп йөргән кыр үрдәген аткан да, пешереп ашарга ниятләп, ут өстендәге казанга салган. Бер көн кайнаган үрдәк, ике көн, өч көн... Һаман пешми икән. Җиденче көн дигәндә, серле үрдәк казаннан күтәрелеп, зәңгәр һавага очкан...

Шул көннән соң Гашыйклар тавының матурлыгы күзгә күренеп сулган, күле корыган...

Борынгы риваять.

I.

Бу юлы командировкам мине Себергә, Юрга каласына китерде. Себер дигәч тә, табигатьнең бездән әлләни аермасы юк: нәкъ бездәге шикелле яшькелт-сары яфракларын кояр-коймас утыручы ак каеннар, бакчаларда — көз явын алырлык август чәчәкләре... «Анда суыктыр» дип алган җылы курткамны да салып кулга тотарга туры килде. Каршы алырга төшүче өлкән яшьтәге Хәнәфи ага мине кунак йортына урнаштырды да үзенә алып китте. Хатыны Сәлимә апа бик җылы каршылады. Икесенең дә туган ягы — шушында. Хәнәфи ага шуннан сугышка киткән, яраланган, тагын үз заводына эшкә кайткан: «Туган туфрак үзенә тарта, шунда тудым, шунда үләрмен дә инде»,— ди. Сәлимә апа яратып, шаяртып кына, кул селтәгән була:

— Әй, картлач, әллә ничә тапкыр үлдең инде... Хәзер чынлап үлсәң дә ышанмыйм...

Чыннан да, Сәлимә апа ике тапкыр «ирегез Хәнәфи Вафин геройларча һәлак булды» дигән хәбәр алган, бөтенләй өмете өзелгәч тә көткән...

Мин, шәһәр Советы тарафыннан рәсми чакырылганлыктан, кичен халык белән очрашуга бардым. Үземнең әсәрләремне укыганнан соң, күп кенә сорауларга җаваплар бирергә дә туры килде. Әмма иң кызыгы алда иде әле. Шушында, Татарстаннан бик ерак Себер шәһәрендә, татар яшьләре бергә җыелып, ансамбль оештырганнар: алар бергәләп сөенәләр, бәйрәм итәләр, үзара кайгыларын уртаклашканда да җырлыйлар, үз моңнарын кичен культура сараенда халык белән дә уртаклашалар. Хәнәфи ага исә үзе — житәкче, үзе — менә дигән конферансье. Ансамбльнең исеме дә бик лирик — «Сагыну». Әллә кайчаннан таныш безнең як көйләре биредә бигрәк тә ягымлы ишетелә икән. Тукта... Ә монысы нинди җыр? Мин ишетмәгән-белмәгән, безнең якларда җырланмаган көй. Озын кара толымлы, кара күзле кыз җырлый:

Кыр үрдәген аттым очкан чакта...
Җаным әрни көн-төн: ник аттым?
Хәзер үзем яралы кош сыман:
Кайтыр юлларымны югалттым.
«Туган якларыңа кайт! Кайт!» —
диеп,
Пар үрдәкләр тезелеп киткәндер,
«Кайта!» — диеп өзелеп көткәндер
дә
Көтә-көтә түземе беткәндер.
Яралы кош, бәлки, кайтып житәр...
Мин давылдан инде ычкынмам.
Танырсыңмы, юкмы, мин булырмын
Кош тавышы белән кычкырган...

Кичә тәмамланды. Ансамбль яшьләре мине кунак йортына озата киттеләр. Мондый җылы август төнендә җәяү йөрүгә ни җитә,— трамвайга да утырмадык. Алар, шул җырны җырлап, төнге урамнар буйлап баралар:

Танырсыңмы, юкмы, мин булырмын
Кош тавышы белән кычкырган...

Хәнәфи агадан иплә кенә сорыйм:

— Нинди җыр бу? Кем язган?

— Аның исеме юк иде. Без аны «Яралы кош» дип атадык. Аның авторы — шушы ансамбльне оештыручы. Мин аның шәкерте генә.

— Үзе кайда соң? Исәнме?

— Исәнлеген исән... Килә алмый...

Мине кунак йортына кадәр китерделәр дә, тыныч йокы теләп, өйләренә таралдылар. Икәүдән-икәү генә калгач, Хәнәфи ага башлаган сүзен дәвам итте:

— Казаннан икәнегезне белгәч, җырның авторы сезне бик күрәсе килүен әйтте. Сез иртәгә ничек тә вакыт табыгыз инде, үзем илтеп куярмын. Хәерле төн!

Бу төнне бик озак йоклый алмый яттым, нинди сере бар бу җырның? Көен дә, сүзен дә үзе чыгарган, диләр. Мондый җыр ниндидер авыр хәлләр кичергән кешенең йөрәгендә генә туа ала. Нинди язмыш аны туган җиреннән аерган икән?

Икенче көнне Хәнәфи ага, машинасына утыртып, мине Юрга урамнары буйлап алып китте. Шәһәр әлләни зур түгел, халык берән-сәрән генә күренә. Шоферга мондый юлларда йөрү рәхәттер. Биш катлы өй янында машинасын туктаткач, Хәнәфи ага мине икенче каттагы квартирга алып менде. Звонок шалтыратты, ишекне ачып, өй эченә атлады, ымлап, мине дә артыннан ияртте. Хуҗаның үзен күргәнче, мин аның: «Керегез!» — дигән карлыккан тавышын ишеттем. Ак күлмәк, кара чалбар кигән, кыска буйлы, ябык чырайлы кеше коляскада утыра иде. Сүзсез генә чишендек. Сул кулы белән коляска тәгәрмәчен тәгәрәтеп, хуҗа түргә юнәлде:

— Узыгыз!

Хәнәфи ага ымлап креслога күрсәтте дә:

— Берәр сәгатьтән килеп алырмын,— дип, китеп тә барды.

Сүзне нидән башларга белмичә, икебез дә аптырабрак тордык. Бүлмә тулы ал гөлләр: тәрәзә төпләрендә дә, өстәлдә дә, стенадагы асылмалы чүлмәкләрдә дә... Бер кырыйда — вак балыклар йөзеп йөргән аквариум. Эчендә — камыш сабаклары... Хуҗаның игътибар белән күзәтүен тоеп, мин уңайсызланып киттем. Ниһаять, ул телгә килеп:

— Мин сезне көттем,— диде. Авызының бик авыр ачылуын шәйләп, бу сөйләшүнең аңа җиңел түгеллеген сиздем. Аның ярты гәүдәсе хәрәкәтсез иде...

— Сез Татарстаннан бит, шулаймы?

— Әйе. Тумышым белән Башкортстаннан.

Ул коляскасын миңа якынрак тәгәрәтте.

— Шулаймыни? Кемнәрегез бар анда?

— Әни. Әти.

— Димәк, кайткалыйсыз?

— Сагынган саен. Моннан кайтышлый кереп чыгарга исәп.

— Таллыкүл авылын белмисезме?

— Белмим шул.

— Гашыйклар тавы турында ишеткәнегез бармы?

— Гашыйклар тавы... Безгә әлләни ерак түгел ул. Аның легендасын безнең тирәдә дә сөйлиләр... Җиде көн казанда кайнагач очкан кыр үрдәге...

— Әйе... Әйе! Ул легенда... чындыр, бәлки...

Ул зәңгәр күзләрен мөлдерәтеп миңа карады:

— Таллыкүл авылы Гашыйклар тавына терәлеп тора... Әгәр мин әманәт тапшырсам... Сез анда бара алмассызмы?

— Нинди әманәт бит?

— Сез кичә «Яралы кош»ны тыңладыгызмы?

— Әйе. Аны сез чыгарган диләр, дөресме?

— Дөрес.— Ул, башын иеп, арган кыяфәттә, бераз дәшми торды.— Әманәтем шул: «Яралы кош»...

— Кемгә тапшырырга?

— Таллыкүл: Мөнирә Идрисовага.

— Ничек?

— Менә сезгә — магнитофон. Эчендәге тасмада — «Яралы кош». Үземнең тавыш. Мөнирә җырны ишеткән иде. Кем икәнне әйтмәсәгез дә, җырымнан мине — Сәет Зилаеровны танып алыр...

— Аңладым. Тасмасын гына бирегез. Үз магнитофоным бар.

— Рәхмәт, якташ.

— Белергә яраса, кем соң ул Мөнирә?

— Сөйләве авыр...

Сәет ага үзенең коляскасын читкәрәк тәгәрәтте, аквариум янында туктап, эчендәге балыкларның кагылуыннан талгын гына тирбәлеп-тирбәлеп куйган камышларга текәлде.

— Сез мине аңларга тырышыгыз... Беренче тапкыр мин аны урманда күрдем. Их, безнең Таллыкүл урманнары! Ярты дөньяны әйләндем дигәндәй, юк андый урманнар беркайда! Урманчы әтием үлгәч, Таллыкүл участогына мине, унтугыз яшьлек егетне, куйдылар. Киләм бер заман шулай урман буйлап, үз уйларыма бирелеп, кошлар тавышын тыңлап... Шул чак, колакка ялгыш ишетеләме дисәм, юк, чыннан да кемдер нечкә генә, көйле генә тавыш белән аваз бирә:

— Ау-у-у!

Андый хәлләрне күргәнем бар: кемдер адашкандыр. Үн чакрымга ишетелерлек тавыш белән җавап бирәм:

— Э-һе-й-й!

Сез мине аңларга тырышыгыз: урманда туган баланың колагы сак: кошлар әнә шулай бер-берсен эзлиләр. Барып чыктым йөгерә-йөгерә Түгәрәк болынга, күрәм: кәрзин тоткан, зәңгәр күлмәк кигән, ялан башлы кечкенә кыз каен төбенә утырган.

— Нишлисең син монда?

— Күрмәйсеңмени ния, адаштым ич...

Безнең якта шулайрак, көйләбрәк сөйләшәләр. Сез аңларга тырышыгыз, кызның җыр кебек сүзләре, беленербеленмәс кенә тибрәлгән йомры күкрәкләре, яндырып алган коңгырт күзләре әллә нишләтте дә куйды...

— Кем кызы соң син?

— Кара, танымайсыңмыни, Сәет абый, түбән оч Мөнирә ич мин...

— Сафа абзый кызымы?

Ул, таныганга сөенеп, сикереп үк торды:

— Әйе... Тугызынчы класс укучысы Мөнирә Идрисова...

Бу сүзләре белән кыз минем дөрләгән хисләремә бозлы су сиптемени: иреннәре җиләктән алсурак тоелган сөйкемле кыз — укучы бала гына икән...

— Әйдә, өеңә кайтарып куям...

Нәни генә, йомшак кына кулларына кагылгач, йөрәгем сулкылдап, тәнем дерелдәп китте. Ул, куркынып, кулларын тартып алды да, поши баласы сыман, читкә ыргылды:

— Тотмагыз! Үзем дә кайта беләм!..

Һәм китте... китте урман сукмагыннан. Беркем дә белмәгән, үзем генә йөргән сукмаклардан. Тукталмакчы булдым, юк, мөмкин түгел, үземнәнүзем аның җилфердәгән зәңгәр күлмәгенә тартылам, иярәм.

— Мөнирә... тукта, сеңелем...

Туктады Сафа кызы Мөнирә. Кинәт кенә борылды да, мин генә ишетелерлек итеп, пышылдады:

— Мин... адашмадым...

— Кара урманда ялгызың нишләп йөрисең соң болай, кыз бала?

Ул, кызарып, башын түбән иде:

— Мин сезне яратам, Сәет абый,— диде. Шуннан йөзен куллары белән каплады да кара урман эченә кереп югалды. Сез аңларга тырышыгыз, якташ, минем нинди хәлдә калганны. Уналты яшьлек кыз сиңа мәхәббәтен ачыктан-ачык белдерсен әле... Юк, балалыктан күчү чорының хыялый бер җилпенүедер бу дип, үземне тынычландырам. Әмма зәңгәр күлмәген тибрәндереп, күз алдыма Мөнирә килеп баса. Әллә инде үзем дә гашыйкмы? «Юк, ярамый, син олырак кеше, тыел!» — ди акылым. Ә йөрәк буйсынмый: «Кызның яшьлек тилерүе генә булмаса ярар иде»,— ди. Үземне тиргим, аны онытырга тырышам. Әмма хыялымда — Мөнирә. Ул узган сукмакларда, болыннарда йөрим, иреннәрем: «Мөнирә, Мөнирә»,— дип кабатлыйлар. Тагын килеп чыкмасмы дигән өмет мине шул кадерле урыннарга китерә. Таллыкүл урамнарыннан, мәктәп яннарыннан урыйм, ул яшәгән өй яныннан узам. Тәрәзә төпләрендәге ал гөлләре арасыннан зәңгәр чәчәгемне күрермен дип хыялланам. Аңлыйм: хәзер ул үз хисләреннән, мәхәббәтеннән качып йөридер.

Икенче тапкыр мин аны клубта укучылар концертында күрдем. Араларында гармунчы булмаганлыктан, мине чакырдылар:

— Бер укучыбыз «Җиләккә дип барган идем»не җырлый, зинһар, коткар,— дигәч, әлбәттә инде, ризалаштым.

— Концертыбызның чираттагы номерында Таллыкүл яшьләренең яраткан җыры: «Җиләккә дип барган идем». Җырлый Мөнирә Идрисова. Гармунда — Сәет Зилаеров!

Гармунымны күтәреп сәхнәгә чыгам, әллә инде тез буыннарым калтырый, үз хәлемне үзем генә беләм... Сәхнәдә, янымда гына ап-ак күлмәк кигән, аккош сыман озын ак муенлы Мөнирә. Ул бит минем белән җырлыйсын белмәде. Нишләр, халыктан оялып, сәхнә артына кереп качмасмы? Көйне ахырынача җырларга үзендә көч табармы? Гармунымның көмеш телләренә башта курка-курка гына кагылам, аннан, әллә гармуннан, әллә тирәннән — күңел түреннән сихри авазлар агылуын тоеп, кыюланам, үзем дә көй дулкынында тирбәләм.



Карурманга барган идем,
Юри генә адаштым.
Сине күргәч, телсез калдым,
Адаштым дип алдаштым.
Синең йөргән юлларыңда
Җиләкләрем түгелде,
Кырын каравыңны белгәч,
Күңелләрем сүрелде.
Җиләкләргә бармам инде,
Бармам, адашмам инде,
Карурманда адаштым дип,
Бүтән алдашмам инде.

Җыр тәмамлануга, без сәхнәнең ике ягына ташландык. Әйе, ташландык. Мин, шашкан адәм кебек, әллә сөенечтән, әллә көенечтән туп-туры кара урманыма чумдым. Хәзер мине аңласа бары тик караңгы урман гына аңлый. Бу кадәр бирелеп, бу кадәр өзелеп беркайчан да уйнаганым юк иде. Үземнең кайдалыгымны таң аткач кына белдем: күлдә йөргән кыр үрдәкләренә карап утырам, үзем һаман җырлыйм икән...



А. ТИМЕРГАЛИНА рәсеме.

Өлгергән ич димәгез,
Җиләкләргә тимәгез.
Миндәй дивана булырсыз:
Яшь кызларны сөймәгез!

— Сез су эчә-эчә тыңлагыз, якташ...

(Сәет ага тәгәрмәчен тәгәрәтеп өстәл янына килде, сусавын тоеп, аның тустаганына су салдым).

Аннан соң... мин салкыннан калтыранган тәнем белән янда гына Мөнирәнең кайнар сулышын сиздем.

— Сәет абый... беләм... Сез мине яратмыйсыз... мине бала дип уйлыйсыз... Сау булыгыз... мин башка килмәм...

Аны әллә кулларым, әллә тыннарым белән тартып алдым, әллә ул кочагыма үзе килеп керде, әллә ике омтылыш бергә туры килде, хәтерләмим, шулай да, ул тыпырчынып, эсселесуыклы кочагымнан ычкынганчы, әйтеп өлгердем:

— Мөнирәм... яратам...

Сез мине аңларга тырышыгыз, якташ, шундый сафлык, пакьлек, гөнаһсыз сак хәрәкәтләр...

Гөнаһ шомлыгына каршы, Сафа абзый, нидәндер шикләнеп, кызы артыннан күзәтеп, эзләп килгән икән. Мин аның ямьсез тавыш белән:

— Эт сөйрәгере кыз! Менә син нишләп йөрисең икән! — дип акыруыннан айнып киттем һәм Мөнирәнең урман эченә кереп качуын күреп калдым.

Аңласагыз иде, якташ, хәлләремне... Мине, балигъ булмаган кызны ялгыш юлга юнәлтүдә гаепләп, комсомол секретаре вазифасыннан азат иттеләр. Мөнирәне каты куллы әтисе чыбыркы белән кыйнаган, әнисе якламаса, тагын да яманрак буласы икән. Әмма бернинди чаралар да безне аерырлык түгел иде инде. Без бик сирәк кенә, яшеренеп кенә, урман сукмакларында очрашуларны дәвам иттек. Их, якташ, нигә соң мин шагыйрь булып тумаганмын, язып бирер идем мин сезгә... тел юк... тел!

Сугыш башланган айны аңа унсигез яшь тулды. Яуга китү хәбәрен көз көне алдым. Ни өчендер Таллыкүлнең киек кошлары бер киткәч кире әйләнеп кайттылар. Мөнирәнең күзләрендә — шом.

— Сәет абый, кошларның кире әйләнеп кайтуы пошаманга төшерә... әллә нинди уйлар килә...

Шома чәчләреннән сыйпап, юатам:

— Бер дә борчылма! Юлларында ни дә булса очрагандыр... Сугыш, афәт!

— Хәерле юлга чыксаң ярар иде, Сәет абый...

— Безнең сәгать сукты, Мөнирә, әйдә, Гашыйклар тавына менәбез!

Мин сезгә Гашыйклар тавы турында сөйләмәдем бит әле. Авылның югары очыннан, күл яныннан күтәреләсең. Элек-электән килгән гадәт: гашыйклар шул тау башына менеп, берберсен ташламаска, мәңге тугры булырга, шушы урында очрашырга вәгъдә бирешәләр. Кем дә кем вәгъдәсен боза, күр дә тор, аңа нинди дә булса бәла-каза килә: я авырый, я үлә, я бәхетсез язмышка дучар була, диләр... Ай-һай, белмим, легенда микән?.. Без дә, ике гашыйк, төн уздырып, таңны каршылау өчен, Гашыйклар тавына күтәрелдек. Аста, миллион төсләр белән таң нурында җемелдәп, Таллыкүл ялтырап ята. Анда — юллары бүлен-

гән, китәлми калган киек кошлар... Ул, кочагыма керә-керә, үзендә шаярырлык көч таба:

— Кара аны, үлеп-нитеп калсаң, өйгә кайтып керәсе булма!

— Синең янга кайтмыйлармыни, Мөнирәм! Яз җиткәч, кошлар белән кайтып җитәрмен.

МӨНИРӘ. Вәгъдәме?

СӘЕТ. Вәгъдә, кадерлем. Шунысы жәл: туй ясарга өлгермәдек. Кайткач инде... Мәнә син шушы яшьлегең, чибәрлегең белән ятларга карамассыңмы, көтәрсеңме мине?

МӨНИРӘ. Көтәрмен, Сәет абый, кайта гына күр. Юлларың бүленеп, озаграк кайталмый торсаң да, гел-гел көтәрмен!

СӘЕТ. Көт, Мөнирәм, көтсәң, мин үлмәм, һичшиксез кайтырмын!

МӨНИРӘ. Безне берниндн дошман да, сугыш да аера алмас, Сәет абый...

СӘЕТ. Мөнирәм, әйтмичә китә алмыйм. Мин кичә кыр үрдәген аттым...

МӨНИРӘ. Аттың? Кыр үрдәген? Сәет абый, нишләдең? Нигә? Ни өчен?

СӘЕТ. Мин урманчы гына түгел, сунарчы да... Кыр үрдәге белән сыйланып, төне буе Гашыйклар тавында синең белән утыру иде исәбем...

МӨНИРӘ. Хараплар иткәнсең, Сәет абыкаем... Үтердеңме?

СӘЕТ. Үлмәде бугай. Күлгә килеп төшкәч, эзләгән идем, табалмадым. Мөгаен, яраланган гынадыр... Ана үрдәк булды бугай... Балалары...

МӨНИРӘ. Легенданы онытгыңмы әллә, Сәет абый?

СӘЕТ. Әй, ышанма иске йолаларга... Берни дә булмас!

МӨНИРӘ. Хәерлегә юрыйк. Нигәләр аттың, Сәет абый! Үзең кошлар белән кайтып җитәрмен дисең...

СӘЕТ. Кайгырма, Мөнирә, бер үрдәген югалтканнан Таллыкүл корымас. Без язмыштан өстен яңа чор кешеләре! Оныт... Кара минем күзләремә... Сөясеңме мине, әйт Таллыкүл буйлары ишетерлек итеп!

МӨНИРӘ. Сөям, Сәет абый, мин — мәңгегә синеке!

СӘЕТ. Алайса, сөюебезне җыр белән раслыйк!

Әкрен генә гармунымны сыздырып җибәрдем — без икәүләп, әтиләр-әниләр телендә дә тибрәлгән таныш көйне җырладык:

Ниндидер моңлылык,
Ниндидер шомлылык
Карурман шавында.
Онытыйк шомнарны,
Каршылыйк таңнарны
Гашыйклар тавында.

Юатма, көйләмә,
Күп сүзләр сөйләмә
Мәхәббәт турында.
Чын сөю юллары
Югары, югары —
Киек кош юлында.

Аерылу таңында
Сөйләшик барын да...
Ант бирик тагын да.
Аерым да, бергә дә
Булыйк гел үрләрдә —
Гашыйклар тавында!

Сез мине аңларга тырышыгыз, якташ... Гашыйклар тавыннан төшкәндә, без ир белән хатын идек. Шул көнне мин фронтка китеп бардым.

Аннан соңмы? Аннан соң мәхшәр, кыямәт... Сугыш, чигенү, окоп, үлеш, кырылыш... Шулай да мин, инде үлдем дигәндә дә, Мөнирәне уйлап, исән кала килдем. Дошман тылында йөрдем, үлекләр өстеннән шуыштым, чәнечтем, үтердем! Бер ел, ике, өч ел утбозлы су эчендә. Гүзәл кыз Мөнирә, Гашыйклар тавы хыялый яшьлекнең идиллиясе булып кына сагындыра. Өстеңә бомбалар коелганда, һәр адымда үлем сагалаганда, яшьлек хыяллары күмелә икән, якташ... Сез мине аңларга тырышыгыз... Камалышта калып, күпме ач йөрдем, яраландым, әсирлеккә эләктем, качтым, партизан булып сугыштым, тагын үзебезнең якка чыктым, башка частька кушылдым. Өйдәгеләр өчен мин — батырларча һәлак булган... Ниһаять, яраланып госпитальгә эләктем. Әлләни авыр яра түгел, тәмугтан котылган безнең иште солдатка — санаторий. Сугыш бетәргә инде күп калмаган, күкрәктә орден-медальләр ялтырыйчылтырый. Кулда — немец аккордеоны...

Атландым атның биленә,
Киттем герман иленә,
Герман җире — яшел үлән,
Я кайтам да я үләм!

Яшәп калырга кирәк аз булса да! Шнапс чөмерәбез, типтерәбез, кызлар белән гулять итәбез дошманның үз оясында! Шундагы Ләлә исемле медсестрага ияләште куйды Сәет абзагыз! Көн саен очрашабыз, тәмам ир белән хатынга әйләндек. Рәхәт тормышны үзебез сугышып алдык, исән калдык, шуның кадерен белеп кенә яшисе хәзер! Тотарга да Ләләнең туган җиренә — Себергә ычкынырга! Фашистның муенын борган бездәй ир-егетләргә кайда да бер — Себер дә үзебезнеке! Кем көтә анда яшьли һәлак булган солдатны? Мөнирә... Ул инде, хәбәр алу белән, онытып, кияүгә чыккандыр... Бетте сугыш, калдым мин исән, киттек без Ләлә белән бергәләп Себергә! Менә шулай уйлады ул чак егерме биш яшьлек Сәет Зилаеров...

Еллар узды, якташ, җилләр исте үзебезнең Таллыкүлне искә төшереп, сулар акты тын гына тирбәлеп, атылган үрдәкне, юллары бүленгән киек кошларны хәтерләтеп... Тауга менгәндә тын кысыла башлады... яшь чакларны, Гашыйклар тавын сагындырып... Мин түгелме саф җанлы табигать баласы Мөнирәгә: «Кайтырмын, көт!» — дигән егет? Ничек тә аңларга тырыш, якташ, гомерем соңгы елларда — тоташ газап... Ник кайтмадым Таллыкүлгә, мин бит вәгъдәләр бирдем Мөнирәгә... Гөнаһсыз, чиста күңелле кыз, бәлки, мине көткәндер тилмереп... «Ниләр генә булса да көтәм,— диде,— мин сиңа ышанам»,— диде. Әллә ничә тапкыр кайтырга, үлгәнче Мөнирәдән бәхиллек сорарга, гафу үтенергә ниятләп карадым, дүрт ел үлем белән көрәшеп җиңеп кайткан гвардеецның шуңа батырлыгы җитмәде... Менә хәзер, бик теләсәм дә, кайта алмыйм. Вәгъдәгә хыянәт... Риваятьнең дәвамы... Иске хорафатларга ышанмасам да, кайчак шикләнеп куям: әллә, мин әйтәм, Таллыкүл үрдәген аткан өчен язмыш үземне каһәрлиме? Кирәк бит: нәкъ кыр үрдәген аткан уң кулымны паралич сукты. Исемдә: мәчет манарасын кискән бер авылдашымның кулы корыган дип сөйләгәннәр иде... Юк, бу факт дин файдасына түгел — бары тик психологиягә бәйләнгән: кеше гомер буе шул гөнаһы өчен газаплана, гел шуның турында уйлый, шул ырым дөрестер, дип куркып яши һәм организмның иң көчсез шул урыны хәрәкәтсез кала. Акыллы бабаларыбыз шуны белгәннәр, димәк. Инде бөтен өмет сездә, якташ... Зинһар, «Яралы кош»ны аңа җиткерегез... Кияүгә чыгып, балалары булса да... Бары тик үзенә генә... Башка бер сүз дә әйтмәгез. Җырдан ул барысын да үзе аңлар: минем исәнлекне, газапларны, хыянәтемне, мәхәббәтемне...

— Хатыныгыз? Ләлә?

— Ул барысын да белә. Яшермәдем. Сез киләсен белгәч, уңайсызламас өчен чыгып китте. Ул үзе болай әйбәт хатын, әмма бәхетсез. Мин үзем дә бәхетсез инде, фактически. Балалар да булмады, ичмасам...

Сәет ага арган, сүнә барган күзләре белән ялварып карады:

— Әманәтне тапшырырсызмы?

— Ышана аласыз. Таллыкүлгә барырмын. Мөнирәне эзләп табармын.

Җырны тагын бер тапкыр искә төшерергә теләптер, ахры, ул сул кулы белән өстәлдәге магнитофонны көйләде, аннан Сәет аганың өзгәләнгән тавышы ишетелде:

Хәзер үзем яралы кош сыман:
Кайтыр юлларымны югалттым...

Билгеләнгән вакыт узып, мине алырга Хәнәфи ага килгәндә, без инде саубуллаша идек. Сәет ага, оясыннан чыга алмаган, канатлары каерылган кош кебек, талпынып куйды:

— Сез бәхетле: Таллыкүлне, аны күрәсез... Сәлам барысына да... Таллыкүл камышларына... Гашыйклар тавына... Зинһар, андагы хәлләрне сөйләп, миңа хат языгыз яки Хәнәфигә шалтыратыгыз. Көтәрмен...

(Дәвамы бар).



Шифалы үсемлекләр

БАЛЛЫ ЧӘЧӘК



Иртә язда чәчәк ата торган үсемлекләрнең берсе — **баллы чәчәк** (первоцвет, аны нәүрүз чәчәге дип тә атыйлар). Бу күпьеллык үсемлекнең сырлы яфраклары тамыр өстенә якын урнашкан.

Әлеге үсемлек урман аланнарында, бик куе булмаган урманлыкта үсә. Аның чәчәге озын сабакка урнашкан, ачык сары төстә була.

Урман юллары кипшенгәнче, ул инде күз явын алырдай булып алтынсу чәчәген балкытып та утыра. Кайбер җирләрдә ул саргылт келәм шикелле үсә.

Язның бу беренче чәчәгенең берничә төре бар. Ул безнең якларда да үсә.

Баллы чәчәктә С витамины башка бакча яшелчәләре — редиска, сельдерей, петрушка, укропка караганда берничә мәртәбә күбрәк.

Ул — кыйммәтле шифалы үсемлек. Медицинада аннан ясалган препаратлар какырткыч чара буларак кулланыла.

Әлеге үсемлек — ашарга яраклы. Бакчада яшелчәләр өлгергәнче, аның яшь яфракларын файдаланалар. Алардан язгы витаминлы салат ясыйлар. Аннан аш, окрошка, щи да әзерләргә мөмкин. Кайбер илләрдә, мәсәлән, Англиядә, бу үсемлек кузгалактан өстен санала. Көнбатыш Европада аны чәчеп тә үстерәләр.

Баллы чәчәк салаты ясау өчен 100 г яфрак, 80 г пешкән чөгендер, 25 г яшел суган, 20 г каймак, түбәндәге тоз алына. Яфракны һәм яшел суган кыягын юып турыйлар да, чөгендер телемнәренә куеп, өстенә тоз һәм каймак сибәләр. Табынга бирер алдыннан 10 минутка суыткычка куеп торалар.

Яфраклы ярмалы аш хәзерләү өчен 160 г яфрак, 40 г тары ярмасы, 20 г кишер, 30 г башлы суган, 20 г май, тәменчә тәмләткечләр алына. Башта ярманы пешерәләр, аннан соң туралган яшеллекне, тәмләткечләрне, кыздырылган кишер һәм суганны салып, аш әзер булганчы кайнаталар.

Яфраклардан он ясау өчен баллы чәчәк яфракларын башта күләгә урында киптерәләр дә, киледә төйгәннән соң, мичтә киптереп, иләктән иләп, өсте ябулы пыяла савытка салып куялар. Аны ашка салырга да була. Аш арты эчемлекләренә дә өстәргә мөмкин.

Ит ризыкларына тәмләткеч хәзерләү өчен 10 г баллы чәчәк яфрагы оны, 20 г ачы томат боламыгы, 1 аш кашыгы су алына. Онга суны салып, томат боламыгы белән бергә болгаталар да 2 сәгатькә өстен каплап куялар. Аны табынга биргәндә, ит ризыклары янына салып бирәләр.

ӨЙ АРТЫНДА ШОМЫРТЫМ



Әле кайчан гына шау чәчәктә иде бу агач! Үзенең хуш исле ап-ак чәчәкләре белән кешеләрнең күңелен күтәреп, кәефләрен яхшырткан иде. Инде менә чәчәкләр урынына барлыкка килгән нәни яшел сәйләннәр үсә-зураялар, тиздән мәмрәп пешкән кара шомыртка әйләнерләр.

Без барыбыз да шомырт ашап үскән кешеләр. Элек-электән үк аны туклануда кулланганнар. Әбиләр утырмага килгән кызларны кипкән шомырт белән сыйлый торган булганнар. Аны киптереп куйганнар, төеп онын ясаганнар, камырга кушканнар. Аннан бәлеш пешергәннәр, аның төнәтмәсеннән һәм саркындысыннан файдаланганнар.

Шомырт витаминнарга бай. Аның төелгән онынннан кесәл бик тәмле була.

Кышын һәм язын организмда витаминнар җитенкерәми. Мондый чакта киптерелгән гөлҗимешкә тигез микъдарда шомырт кушып чәй ясыйлар. Ике стакан кайнап торган суга бер аш кашыгы катнашма салып, 5-10 минут кайнаталар да 3-4 сәгатькә өстен каплап куялар. Мондый төнәтмәне термоста да ясарга була. Алда әйтелгән микъдар исәбеннән җимешкә кайнап торган су коялар да барысын бергә термоска салалар. Бер сәгать, сәгать ярымнан соң марля аша сөзеп, эчемлекне чәй урынына эчәләр. Аның салкын тиеп авырганда да шифасы бар.

Үз бакчагызга моңарчы шомырт агачы утыртмаган булсагыз, утыртырга ашыгыгыз. Әлеге агач теләсә нинди туфракта да яхшы үсә, дымлы урынны ярата, салкынга — чыдам, ул нәзберек түгел. Күздән җимеш орлыгын утыртсагыз, язга ул шытып чыга. Өч елда ул метр ярым биеклеккә җитә, ә биш ел узуга сез аның беренче җимешеннән авыз итәрсез. Аның үсентесен тамырландырып утыртырга да була. Болай эшләгәндә ул тизрәк үсә.

Шомыртның чәчәкләре генә дә нинди бит! Аның гүзәллеге шагыйрьләрнең шигъри юлларына күчкән. Ә бакчага файдасы ни чаклы? Күпереп торган куш ак чәчәкләргә бал кортлары күпләп куналар. Димәк, бакча үсемлекләре әйбәтрәк серкәләнә, тизрәк үсә һәм уңышы иртәрәк өлгерә.

Шомырт зарарлы бактерияләрне дә юк итә, зарарлы бөҗәкләрне, сукыр чебенне дә куркыта. Аның чәчәгендә һәм кайрысында актив фитонцидлар бар. Бу агач кайрысы төнәтмәсен кура җиләгенә, карлыганга, крыжовникка сиптерсәң, бөҗәкләр юкка чыгар.



ДУС ХАЛЫКЛАР АШЛАРЫ

Тутырылган тавык *(Никарагуа)*. Тавыкны чистартып юыгыз да, тышкы һәм эчке ягын төелгән кара борыч, тоз белән уып, 5 минут үсемлек маенда кыздырыгыз. Аннары бәрәңге, суган, кишер, сарымсак һәм помидорны ваклап турагыз. Шулпа, борыч, томат соусы салып болгаткач, барысын бергә 15 минут майда кыздырып алыгыз. Аннан соң турап пешкән ит, йөзем, бераз шикәр комы, тоз өстәп болгатыгыз да, яңадан 10—15 минут кыздырыгыз. Шуны тавык эченә тутырыгыз һәм шулпалы кәстрүлгә салып, 1 сәгать кызу мичтә тотыгыз. Пешкән тавыкны редиска, кыяр, помидор белән бизәп табынга бирегез.

Уртача зурлыктагы тавык өчен 300-400 г ит, 2-3 бәрәңге, 3 кишер, 6-8 редиска, 6 помидор, бер төш сарымсак, 3 баш суган, 2 аш кашыгы йөзем, 2 аш кашыгы шикәр комы, 3-4 аш кашыгы томат соусы, 2 аш кашыгы үсемлек мае яисә маргарин, тоз һәм борыч кирәк.

Пылау *(Әфганстан)*. Чистартылган кишер белән суганны озынча итеп турагыз да, кызгылт төскә кергәнче үсемлек маенда кыздырыгыз. Шуңа вак итеп туралган ит, су һәм тоз өстәгез. Аннары аерым савыттагы тозлы суда дөге пешереп алыгыз. Өстенә алда әзерләнгән итле кишер, йөзем, борыч салыгыз да, 15—20 минут уртача кызулыктагы утта томалап пешерегез.

1 кг ит өчен 1 кг дөге, 330 г маргарин, 100 г үсемлек мае, 3–4 кишер, 6–7 суган, 200 г йөзем, кара борыч, тоз кирәк.

Белен *(Вьетнам)*. Иң элек юка гына итеп беленнәр пешерегез. Аннан соң кәбестә белән суганны озынча итеп ваклап турагыз, шуңа чи вермишель, ит фаршы, йомырка, тоз, борыч өстәп болгатыгыз. Барлыкка килгән катнашманы чи килеш белен эченә салыгыз һәм башларын бөкләп торбасыман төрегез. Тутырылган беленнәрне уртача кызулыктагы утта әйләндерә-әйләндерә кыздырыгыз, янына яшелчәләр куеп, табынга бирегез.

Фарш ясау өчен 100 г вак вермишель, суган, йомырка, 200 г май, тоз, кара борыч кирәк.

Кәбестә белән кыздырылган бәрәңге *(Непал)*. Туралган суганны алтынсу-кызгылт төскә кергәнче майда кыздырып алыгыз. Аннары шуңа телемләп туралган бәрәңге, төсле кәбестә өстәп, томалап пешерегез. Бераздан яшел борчак, яшел тәмләткечләр сибеп, кайнар килеш табынга бирегез.

1 кг кәбестә өчен ярты кг бәрәңге, ярты кг яшел борчак, суган, 100 г үсемлек мае кирәк.

Итле кәбестә *(Лаос)*. Итне вак кисәкләп турагыз да, майда кыздырыгыз. Аннары аерым табада озынча итеп туралган кәбестә һәм суган кыздырып алыгыз. Тоз, борыч, яшел аштәмләткечләр сипкәннән соң, барысын бергә томалап пешерегез. Янына пешкән дөге салып, кайнар килеш табынга бирегез.

Ярты кг ит өчен 200 г кәбестә, 100 г суган, ярты кг дөге, 150 г үсемлек мае, борыч, тоз, бераз уксус һәм яшел тәмләткечләр кирәк.

Бәйрәм салаты *(Польша)*. Ипине һәм сырны чәчәк, йолдыз, яфрак формасында кисқәләгез. Ипигә атланмай ягыгыз да, өстенә сыр яисә колбаса куегыз. Аннан соң кыяр, редиска,помидор, гөмбә кисәкләрен шырпы яисә кечкенә таякларга кидертеп, үзегезчә матур итеп барысын бергә тәлинкәгә урнаштырыгыз.



И. РОДИОНОВА
рәсемнәре.

Бәйрәм пирожные *(Болгария)*. Әчегән сөткә йомырка, шикәр комы, тоз һәм он салып камыр басыгыз. Шуны 0,5 см калынлыкта җәегез дә, 10 кисәккә бүлегез. Аннары угычтан чыгарылган брынзага 2 йомырка сытып туглагыз. Барлыкка килгән катнашманы камыр кисәкләренә ягыгыз һәм конвертсыман итеп төрегез. Аннан соң майланган табага салып уртача кызулыктагы мичтә пешерегез.



1 кг он өчен 5 йомырка, ярты стакан әчегән сөт яисә кефир, 300 г брынза, 1 чәй кашыгы шикәр комы, бераз чәй содасы һәм тоз кирәк.

Итле бәрәңге *(Болгария)*. Әрчелгән бәрәңгене кисәкләп турагыз да, шуңа фарш, тоз, су, үсемлек мае, яшел тәмләткечләр өстәп болгатыгыз. Һәм суы парга әйләнеп беткәнче, 30–40 минут мичтә пешерегез. Өстенә сөт кушып тугланган йомырка сипкәннән соң, яңадан 15 минут мичтә тотыгыз.

Ярты кг бәрәңге өчен 250 г ит фаршы, 2 йомырка, 3 аш кашыгы үсемлек мае, 1,5 стакан су, тоз, яшел тәмләткечләр кирәк.

Печенье *(ГДР)*. Тозлы суга маргарин өстәп кайнатыгыз. Аннары уттан алып он салыгыз да, кәстрүлгә ябышмый башлаганчы туглагыз. Бераз суытканнан соң, өстенә йомырка сытып, артык каты итмичә генә камыр басыгыз. Һәм төрле формада печеньелар ясап, кайнап торган үсемлек маенда пешерегез.

200 г он өчен тулыртулмас 2 стакан су, 100 г маргарин, 4–5 йомырка, 200 г үсемлек мае кирәк.

Кекс *(ГДР)*. Эретелгән маргаринга шикәр комы, ванилин, угычтан уылган лимон кабыгы салып болгатыгыз. Аннары сөт, чәй содасы, крахмал һәм он өстәп камыр изегез. Төелгән сохари сибелгән, майланган махсус табаларга салып, 1 сәгать мичтә пешерегез. Кексны суыткаңнан соң, өстенә шикәр оны сибеп, табынга бирегез.

250–300 г маргарин өчен 200 г шикәр комы, 4 йомырка, 400 г он, 100 г крахмал, 6–8 аш кашыгы сөт, лимон кабыгы, аш серкәсе өстәлгән чәй содасы, 2 аш кашыгы шикәр оны кирәк.

Эчемлек *(Кампучия)*. Иң элек ярты литр суга ярты кг шикәр комы салып сироп кайнатыгыз да, тугланган йомырка өстәгез. Тиз генә уттан алып, кашык белән яхшылап болгатыгыз. Бераз суыткач, тәлинкәләргә бүлеп табынга бирегез.

Ярты литр су өчен ярты кг шикәр комы, 15 йомырка кирәк.

ВРАЧ ҖАВАП БИРӘ

«Полимиелит авыруы турында тулырак язсагыз иде. Аны бер яшьтән өч яшькә кадәрге балалар ничек кичерәләр, ул аларның алдагы тормышына ничек тәэсир итә?

Г. С. Мамадыш районы.»

Полимиелит — вируслар китереп чыгара торган үзәк нерв системасы авыруы. Бу авыру белән гадәттә балалар чирли. Вирус бер кешедән икенче кешегә авыруның беренче атнасында пычрак куллар, юылмаган яшелчә, йорт әйберләре, уенчыклар аша йога. (Кайчакта чебен дә чир таратучы хезмәтен үти). Полимиелит төрле кешедә төрлечә уза: берниндн авыру билгеләре булмаган җиңел формалардан алып паралич белән тәмамланган авыр формаларына кадәр.

Авыру кинәт югары температурадан башлана. Аппетит бетә, эч авырта, эч китә, баш-арка, аяклар сызлый, йокы баса, күзән җыера. Гомумән баланың хәле беренче атнада бик авыр була. Еш кына 7-8 көннән температура төшә, баланың хәле яхшырган кебек була. 2-3 көннән яңадан температура күтәрелә. Менингит авыруындагы кебек баш авырту, җилкә авырту көчәя. Авыруларның йөрәк тибеше ешая, авыру тирли, тынычсызлана. Паралич сугу кисәк була, ул авыруның 3-5 көннәренә туры килә. Баланың аяклары йөрмәс була. Аяклар сызлау 1-2 ай дәвам итә, аннан акрынлап, бала хәлләнә башлагач, аягына баса башлый. Баштарак терелү процессы тизрәк булса, ярты еллар узгач ул акрыная бара. Параличның ахыры төрле кешедә төрлечә бетә: кайбер балалар яңадан аякка басып йөри башлыйлар, кайберәүләр инвалидлыкка чыга. Паралич аяк мускулларын гына түгел, кайчакта кул, арка, күкрәк яки бит мускулларын да җәрәхәтли.

Авыруны беренче көннән үк больницага салып дәвалыйлар. Авыртуны баса торган тынычландыргыч дарулар, физиотерапия ысуллары кулланалар. Азык витаминнарга бай, туклыклы һәм тәмле итеп пешерелгән булырга тиеш. 3-6 айлардан соң ләпек белән дәвалау, массаж кулланыла. Махсус санаторийларда (мәсәлән, Евпатория, Одесса, Цхалтуба) дәваланунын да аяккулның эшчәнлеген күтәрүдә әһәмияте бик зур. Дәвалау физкультурасын авыруның бөтен стадияләрендә кулланалар.

«Мин ревматизм белән авырыйм. Соңгы елда аякларым шешә башлады. Бу авыруны дәвалап буламы?

М. С. Актаныш районы.»

Ревматизм — йөрәк, кан тамырлары системасын, буыннарны, организмның тоташтыручы тукымаларын зарарлый торган авыру. Бу авыру еш кына төрле ангиналардан, сулыш юллары ялкынсыну процессыннан соң башлана. Аның сәбәбе булып стрептококк инфекциясе исәпләнә. Стрептококк организмның сизгерлеген үзгәртә, тоташтыручы тукымаларны зарарлый, организмның авыруларга каршы торучанлыгын киметә. Кеше артык туңганда, кирәгеннән артык талчыкканда, еш кабатланган ангиналардан соң йөрәктә, буыннарда, башка органнарда аллергик ялкынсыну хасил була. Йөрәкнең эчке сүрүе ялкынсынуы эндокардит дип атала. Эндокардит йөрәкнең клапан аппараты зарарлануга китерергә мөмкин. Кайвакыт йөрәкнең мускул тышчасы да ялкынсына.

Ангина, грипп, тонзиллит, тын юллары ялкынсынуыннан соң, гадәттә бер-ике атна үткәч, кешенең температурасы күтәрелә, ул хәлсезләнә, буыннары сызлый башлый. Буыннар авыртып кына калмый, алар шешә, буын тирәсе кызарып чыга. Аз гына кыймылдаганда да авырту көчәя. Бу хәл 3-4 көнгә сузыла. Башта бер буын, аннан икенче буын авырта башлый. Ревматизм вакытында шулай итеп буыннарның зарарлануы «күчмә» характерда була. Вакытында дәваласаң, буыннардагы мондый үзгәрешләр тулысынча бетә. Кайчакта гына авырулар «коры сызлау»дан зарланалар. Димәк, ревматизм йөрәк өчен куркыныч авыру булса да, буыннар өчен әллә ни куркыныч түгел дияргә була. Шуның өчен дә врачлар арасында: «Ревматизм йөрәкне кимерә, буыннарны ялый гына»,— дигән кебегрәк фикер йөри.

●

«Минем бавырым авырта. Аны ничек итеп дәвалау, нинди ашамлыклар белән туклану турында киңәш бирсәгез иде.

С. Р. Арча районы».

Барлык төрле бавыр авыртуын бер термин белән гепатит (грек сүзе һепатос-бавыр) дип атыйлар. Бавыр авыруларын китереп чыгаручы сәбәпләр күп төрле. Мәсәлән, инфекцион гепатит — сары авыруы (бу йогышлы авыру). Химик матдәләр белән агуланганда бавыр шешә. Моңа промышленность агулары, дарулар, азык-төлек белән агуланганда хасил булган бавыр авырулары керә. Матдәләр алмашы бозылу нәтиҗәсендә барлыкка килгән төрле токсико-аллергик гепатитларны китерергә мөмкин. Кайчакта бавыр авыруы нәселдән дә килә.

Бавыр шешкәндә гадәттә ул зурая, авырта. Бигрәк тә бавыры авырткан кеше майлы азык ашаса, аракы эчсә бавыр үзен шундук сиздерә. Аппетит бозылу, косасы килү, хәлсезлек башлана.

Бавыр авыруына диагноз кую өчен беренче чиратта эпидемиологик ситуацияне белү бик мөһим. Биохимик юл белән кан анализын тикшерәләр, клиник күзәтүләр авыру сәбәпләрен ачыкларга ярдәм итә. Дәвалау гепатитның формасына карый.



Мәсәлән, сары булганда авыруны больницага салалар. Бавыр авыруы хроник формада булганда диетаның роле бик зур: иң беренче чиратта авыр эшкәртелә торган майлы азыкларны чикләргә кирәк. Эремчек, сөт азыклары, майсыз ит, балык тәкъдим ителә. Витаминлы азыклар, яшелчә-җимеш ашау бавыры авырткан кешегә бик файдалы. Врач кушкан даруларны гына эчәргә кирәк. Төрле санаторий шартларында дәвалану да бавыр авыруы көчәеп китмәсен өчен тәкъдим ителә.

●

«Якыннан күрү һәм аны төзәтү чаралары турында язсагыз иде.

А. Ш. Апас районы».


Әйберләрне күзгә бик якын китереп карауны медицинада миопия диләр. Бу хакта журналыбызның 1983 ел октябрь санында мәгълүмат биргән идек. Соңгы елларда бу өлкәдә медицина нинди уңышларга иреште соң? Мәскәүнең Гельмгольц исемендәге фәнни-тикшеренү институтында күзне операциясез ныгыту ысулы табылган. Күз агына кубекләнүче полимер кушылмасы кертәләр. Кушылма акрынлап күзгә сеңеп күз агын ныгыта. Бу профилактик ысул, ул күрә карауның көчәюен саклый. Процедура куркыныч түгел. Күзенә мондый полимер салынган кеше 6 ай саен күз врачында тикшерелеп тора.

Руфина ФӘТТАХОВА.
Медицина фәннәре кандидаты.

ҖЫРЛАРДА ҖЫРЛАНЫРЛЫК БУЛСЫН


«Ач тәрәзәң, күтәр
пәрдәң,
Нурлы йөзең күренсен», — дип җырлый халык.


Мондый җырларда җырланырлык тәрәзәләр — көзгедәй, пәрдәләре күз явын алырдай буладыр, могаен. Андый пәрдәләрне һәркем үзе тегә, чигә, челтәрләп ясый ала. Без тәрәзә пәрдәләренең берничә үрнәген тәкъдим итәбез. Мондагы челтәрләр 20 нче номерлы кәтүк җебеннән яки «Снежинка» дигән җептән бәйләнә.














Гөлфия ЮНУСОВА,
«Башкортстан кызы»
журналының
баш редакторы.



Ашыгамын

*Ашыгамын. Кешеләргә
Әйтә торган сүзләрем бар.
Ашыгамын. Алларымда
Үтеләсе үрләрем бар.*

*Ишетәсе моңнарымны
Ишетим әле, тизрәк, дим,
Күпме күрәселәрем бар,
Күрим әле тизрәк, дим.*

*Көтсен мине ярсу язым,
Көтсен мине алтын көзем.
Тиярләргә тисен иде
Вакытында изгелегем.*

*Аермасын җырларымнан...
Күпме килер
кулларымнан...
Ашыгамын, ашыгамын...
Туктатмагыз юлларымнан.*

Әнием сүзләре

*Бәхет башы — намус,
балам,
Намусыңнан аермасын.
Талпынып очар чагында
Канатларың каерылмасын.*

*Жәлләмә һич хезмәтеңне,
Эшләгәннән кеше үлми.
Рәхмәт алып яшәмәсә,
Кеше үзе рәхәт күрми.*

*Булсын һәрчак кешеләргә
Саф күңелең, ачык йөзең.
Жанга уктай кадалмасын
Бәреп әйткән туры сүзең.*

*Кеше кешедән ким түгел,
Шуны, балам, һич онытма,
Йөрәгеңдә беркемгә дә
Гомер буе кинә тотма.*

*Киртеп куй син колагыңа:
Үзеңнән зур булып булмый.
Туган җирләр бирәү була—
Өр-яңадан туып булмый.*

*Яшәү бүләк иттем сиңа,
Буш янмасын, яшәү ул —
ут.
Ана сүзе изге була,
Мин әйткәнне исеңдә тот.*

Безнең таләп

*Җирем тыныч түгел. Җилләр аша
Сөремнәрнең килә ят тыны.
Агрессорлар утлар белән уйный,
Иминлеккә яный ялкыны.
Йокы алмый. Берни сизмичә дә,
Төшләр күреп ята улларым.
Уйлыймын мин туар таң хакында,
Улларымның килер елларын.
Нәрсә көтә сезне, балакайлар,
Нинди булыр сезнең киләчәк!
Саф хыяллар тулы башкаегыз
Ни кичереп,ниләр күрәчәк!
— Мин музыкант булам,— ди берегез,
Чынга аша күрсен бу өмет.
Чайковский, Моцарт, Исмәгыйлов...
Алар моңын, улым, дәвам ит.
Чал тарихы үткән буыннарның,
Бүгенгесе төрле халыкның,
Өлкән улым, бала күңелендә
Син аларга илтер юл таптың.
Туган илне саклап хезмәт итү —
Иң зур теләк сезнең, оланнар.
Барысы да сез дигәнчә булыр,
Тыныч булса гына дөньялар.*

*Тагы төшәм хәвеф-хафаларга
Матур уйларымнан арынып.—
Егерменче гасыр куенында
Зәһәр утлар ята кабынып.
Бер саксызлык... Күккә очачак бит
Бар кешелек, өмет, киләчәк.
Син укыган чал тарих та, улым,
Шартлап челпәрәмә киләчәк.
Кеше акылының меңәр еллар
Иҗат иткән көче, тормышы,
Күкрәп килгән язлар, күк диңгезләр,
Яшәешнең гүзәл булмышы...
Бернәрсә дә җирдә калмаячак,
Юл куелса зәһәр утларга.
Шушы шомлы уйдан йөрәк яна,
Шушы хафа бирми йокларга.
Беләм: менә шушы минутларда
Күпме ана шулай сызлана,
Ак тәнлеме, сары, карамы ул,
Һәр анага газиз үз бала.
«Әлли-бәлли» бишек җырын җырлап,
Күпме ана бала тирбәтә.
Төрле ил һәм раса хатыннарын
Шушы бер җыр бердәм, тиң итә.*

*Һәркайсысы өчен бала хакы
Кыйммәтрәк дан һәм алтыннан.
— Иң зур теләгегез! — дип сорасаң
Бала баккан һәрбер хатыннан,
Ул: «Иминлек җирдә»,— дияр иде,
Һич шик төшмәс мондый җавапка.
Юк, бу сүзләр җавап кына түгел,
Ә әйләнә катгый таләпкә.
Теләгебез изге, хатын-кызлар,
Таләбебез көчле, урынлы.
Зәһәр ут уйнаткан ир әнисе,
Ныграк тыйсаң иде улыңны!
Зәһәр ут уйнаткан ир хатыны,
Гаепле төс синең сыныңда.
Тере калкан булып калыксаңчы.
Бергәнәңнең хәтәр юлында.
Хатын-кызлар яртысыннан күбе
Җир йөзендә бөтен халыкның.
Һәр йөрәкне тетрәндереп үтсен
Хак авазы безнең тавышның.
Тынычлыкны аяп күтәрелгән
Кешеләргә хаклык юл сала.
Миллионнарча изге аналарның
Иң алдыннан бара Җир-ана.*

Әзһәр ГАБИДИ

Үкенмәсме икән?

*Күтәрелгән инде күксел томан,
Тояк тавышлары күптән тынган,
Кыңгыраулы атта иркәм узган,
Күтәрелгән инде күксел томан...*

*Тояк тавышлары күптән тынган,
Күзем алмыйм иркәм киткән юлдан,
Борылыр да кире кайтыр сыман,
Тояк тавышлары күптән тынган...*

*Кыңгыраулы атта иркәм узган,
«Мин синеке!» — дигән антын
бозган,
Үкенмәсме икән соңыннан?! —
Кыңгыраулы атта иркәм узган...*

Кайтса әгәр яшь чагым

*Аргамакка атланып,
Кошлардай канатланып,
Пар өзәңгемне кагып,
Мин китәр идем чабып,
Аргамакка атланып...*

*Кошлардай канатланып,
Юлсыз җирдән юл салып,
Сөйгән ярымны алып,
Мин китәр идем чабып,
Кошлардай канатланып...*

*Пар өзәңгемне кагып,
Чиккән сөлгеләр тагып,
Мәхәббәткә юл ярып,
Мин китәр идем чабып,
Эх, кайтса егет чагым!!!*

Сагынамы чапкан чакларын

*Кырда ялгыз йөри тулпарым,
Өзгәләгән йөгән чукларын,
Сагынамы чапкан чакларын,
Кырда ялгыз йөри тулпарым...*

*Өзгәләгән йөгән чукларын,
Уйнаклатмый бөдрә ялларын,
Яңгыратмый шөлдер моңнарын,
Өзгәләгән йөгән чукларын...*

*Сагынамы чапкан чакларын,
Муенына сөлге такканын,
Яшь киленнәр алып кайтканын
Сагынамы чапкан чакларын?..
Ярсып кешни ялгыз тулпарым...*

Роза ХАФИЗОВА

ӘНИ НИНДИ БУЛА?

ХИКӘЯ

Раксана әнисен бөтенләй хәтерләми. Әнисе аңа заманча яңгыравыклы шушы исемне кушкан да дөнья куйган. Әтисе кем булган, әби-бабасы, туган-тумачалары бармы — болары кызчыкка мәгълүм түгел. Хәер, бу сораулар аны һич тә борчымый иде. Ул яши торган йортта әти-әни дигән сүзләр бик сирәк ишетелә. Раксана аларның мәгънәсенә дә төшенми. Ашыйсылары килсә, алары Галия апалары ашата. Фәридә апа белән Сария апа гел алар янында була. Раксана еласа, көйсезләнсә, зуррак кыз балалар аны юаталар, күтәреп йөртәләр, уенчыклар бирәләр иде.

Раксана бик сөйкемле, көнбагыш чәчәге кебек сап-сары ефәк чәчле, зур зәңгәр күзле, ап-ак йөзле кызчык. Үзе бик хәрәкәтчән, шаян, ятимлекнең нәрсә икәнен дә белми, сизми. Бу йортта ул иң нәние, шуңа күрә аңа игътибар да күбрәк иде. Өлкәннәр аны «төпчек кызыбыз» дип кенә йөртәләр, шуклыклары өчен дә ачуланмыйлар иде. Раксана үзе дә тәрбиячеләрен ярата, һәммәсенә тартыла. Тик үз тирәсендәге өлкәннәр арасында аның иң яратканы Хисам бабай иде.

Хисам карт монда атлар карый, төннәрен каравылда тора, малай-шалайны чүкеч-балта тотарга өйрәтә, ишегалдын тәртиптә тота иде. Аның үз өстенә алган башка вазифаларын да санап бетерерлек кенә түгел иде. Билгеле, балалар йорты штатында аның хезмәт хакы алыр өчен билгеләнгән эше булгандыр булуын. Әмма ул бу йортта үз кеше, аның терәге иде. Балалар һәрчак аның тирәсендә чуалалар. Картның күңел җылысы барысына да җитә иде. Әле тәпи йөри башламас борын ук, бүлмәгә Хисам бабай керүгә, Раксана гөлдер-гөлдер килеп аңа үреләә, сөенә иде. Хисам карт кызчыкны күтәреп ала, сөя, итәгенә утырта, үчтеки-үчтеки итә. Карт китә башласа, Раксана кычкырып елый, җибәрмәскә теләп, аңа ябыша. Еш кына ул бабайның итәгендә йоклап та китә иде. Ул чакта карт аны саклык белән генә урынына илтеп сала. «Раксананы иркәләп бозасың»,— ди иде аңа тәрбияче Фәридә. Ул үзе балаларны кырыслык белән тәрбияләү ягында иде. «Берни аңламый ич әле ул сабый»,— дип кенә җавап бирә иде карт аңа.

Җәйләрен балаларны Кама буена, дачага алып чыгалар. Зурраклар өлкәннәргә бәрәңге, яшелчә үстерүдә булышалар. Кышка җиләк-җимеш җыешалар. Җәйләрен Раксана тулысы белән Хисам бабай карамагында кала. Зуррак балалар иртүк я кырга эшкә, я күрше урманга походка китәләр. Раксана исә берни сизми тәгәрәп йоклый. Ул арада Хисам бабай атлары янында кайнаша. Раксана уянгач, алар икәүләп, басуга, балаларга эчәргә салкын су илтәләр. Бабай Раксананы хуш исле яшел печән өстенә утырта да башына ак панамасын кидерә. Арбага җигелгән Рекорд кушаматлы алаша салмак кына юырта. Хисам бабай кулына дилбегәсен тоткан килеш уйга чумып бара. Ләкин Раксана аңа озак уйланырга бирми, яшел печән арасыннан тәлгәше белән кып-кызыл җиләк, яисә зәп-зәңгәр чәчәк таба да, сөенечен бабасы белән уртаклаша.

— Мин таптым, менә моннан,— ди. Җиләкне берәмтекләп бүлә башлый. Бусы синә, бусы — миңа, янәсе. Кызчык Хисам картның балалар йокыдан торганчы ук күрше урман аланына барып, печән чабуын да, бу җиләкләрне, чәчәкләрне Раксана тапсын дип үлән арасына кыстыруын да белми иде.

Раксана шулай әти-әни сүзен бер тапкыр да әйтеп карамаган килеш, беркемне дә юксынмый үсәр дә үсәр иде бәлки...

Көннәрдән беркөнне Талия исемле кызны алырга әнисе килде. Әнисе исән була торып, моңа кадәр Талия ник бирегә яшәгән? Монысы балалар өчен сер булып калды. Шунысы хак: бик ошатты Раксана Талиянең әнисен. Искитмәле әйбәт апа иде ул. Талия белән рәттән хәтта Раксананы да кочаклап үпте. Балаларның һәрберсенә кәгазенә аю сурәте төшерелгән конфет бирде. Талиянең шатлыгы эченә сыймый иде. Тәрбиячеләр аның документларын әзерләгән арада, әнисенең кулыннан җитәкләп, «минем әнием, минем әнием»,— дия-дия мактанып йөрде. Әнисенең күзеннән яшь ага. Үзе зур, тупас куллары белән кызының чәченнән сыйпый иде. Моңа кадәр гел аерым игътибарга өйрәнгән Раксананың күңелендә көнчелек сыман хис уянды. Ул ярсып барып ананың икенче кулына асылынды, аннары Талиягә телен күрсәтеп: «Минем әни»,— диде. Талия моңа түзеп тора алмады. Әнисенең алдына чыкты да, аны кочаклап, елап җибәрде. «Юк, юк, минем әнием, әйе бит, әни, минеке бит, әйт, әйт»,— дип кабатлады. Раксананың да тиз генә бирешәсе килмәде. Талияне читкә этәреп, анага сарылды. «Минем әни, әйе бит»,— дип ул да Талиянең сүзләрен кабатлады. Балалар моның ни белән бетәсен кызыксынып карап торалар иде. Талиянең әнисе дә аптырап калды. Кызының сүзен җөпләр иде, Раксана бигрәк сабый, әнинең кем икәнен дә белмичә, өзгәләнеп аңа сарыла. Шулчак Фәридә апалары ярдәмгә килде. Ул чүгәләп Раксананы кочаклады да: «Юк, бу апа Талиянең әнисе, тәртипле булсаң, синең әнием дә килеп алыр»,— дип кызчыкны юатты. И куанды Раксана, и шатланды. Тәрбиячeнең муеныннан кочаклап, кабат-кабат сорады:

— Килеп алырмы? Тәртипле булсам, килеп алырмы? — диде. Тәрбиячегә: «Алыр, алыр»,— дип ышандырудан башка чара калмады.

Әнисе турындагы уй Раксананың бөтен барлыгын биләп алды. Йокларга ятканда ул иртәгә көн туасын, бәлки әле ул йокыдан торуга ук әнисе киләсен уйлап ята иде. Шулай булды ич: Талия йокыдан торганда, аның койкасы янында әнисе утыра иде. Моны Раксана үз күзләре белән күрде. Раксана белән Талиянең койкалары группада янәшә тора. Раксана Талиядән иртәрәк уянган иде. Нindидер апаның, кульяулыгы белән авызын каплап, Талиягә карап елап утыруын күрде. Раксананың уянганын күргәч, апа аңа карап матур итеп елмайды. Алга төшкән чәчләрен рәтләп куйды, тураеп утырды. Раксанага никтер бик рәхәт булып китте, ул да елмайды. Шулчак Талия күзен ачты. Аптыраган кыяфәт белән апага карап торды. Апа иелеп аның маңгаеннан үбеп алды һәм пышылдап кына: «Бәбкәм!» — диде. Талия башта югалып калды, аннары ниндидер көч аны апага этәрде. Таныды ул әнисен, йөрәге белән таныды һәм аның муенына асылынып: «Әни, әнием»,— дип кычкырып җибәрде.

Шуннан бирле Раксана, йокларга ятканда, койкасының бер читенәрәк сыенып ята торган булды. Төнлә әнисе килә-нитә калса, иртән аңа утырырга урын булсын, янәсе.

Раксананың әнинең нинди булганын, кайдан килгәнен бик беләсе килә иде. Талиянең әнисе ник Талиянеке генә булган?

Ул үзеннән зуррак кызларны бу сорау белән аптыратып бетерә. Аның: «Әни нинди була?» — дигән соравына кызлар: «Әни әйбәт була, әни ачуланмый, иркәли»,— диләр. Аларның күбесе әле әниләре белән яшәгән вакытларын хәтерли. Ләкин Раксананы бу җавап канәгатьләндерми, әнинең нинди булуы турында түгел, ничек булуы, кем булуы турында да беләсе килә аның. «Тыңламасаң да, тәртип бозсаң да ачуланмыймы?» — дип сорый. «Үз әнием ачуланса да онытыла»,— диләр кызлар. «Минем әни чынлап та мине килеп аламы?» — дип тагын бер кат ачыкларга тели Раксана. «Килеп алырга да мөмкин»,— диләр кызлар. Җирән чәчле Рузинә генә: «Минем әни бик теләсә дә килә алмый. Дөньяда юк ул»,— дип моңсу гына әйтеп куя. Раксана әле үлемнең ни икәнен дә белми. Шуңа күрә: «Ник дөньяда юк»,— дип төпченә. Рузинә җавап бирмичә китеп бара. «Аның әнисе үлгәнгә өч ел инде, Сәкинәнең дә, Светаның, Машаның да әниләре үлгән. Монда әниле кешеләр бик сирәк»,— дип аңлаталар кызлар. «Ничек үлгән?» — дип аңларга тырыша Раксана. «Авырган да үлгән,

аннары җиргә күмеп куйганнар»,— диләр кызлар.

Раксана бу сөйләшүдән соң озак кына уйланып йөри, аннары үз-үзен ышандырып куя: «Минем әни үлмәгән, Фәридә апа әйтте, килеп ала, диде».

Бу көннәрдә яңгырлар яуды. Балалар мунча керделәр, өйдәге эшләр белән мәшгуль булдылар. Шуңа күрә Раксана Хисам бабай белән шатлыгын уртаклаша алмый торды. Яңгырлар туктап, көн аязуга, балалар тагын утауга чыктылар. Раксана бу көнне түземсезләнеп көтеп алды. Бабай янәшәсенә, арбага йомшак печән өстенә менеп утырыр-утырмас ук тәтелдәргә тотынды. «Бабай, бер сүз әйтимме, әйтимме?» — дип кабатлады. Бик дулкынланудан аның битләре янып чыккан. Ул печән арасыннан гадәтенчә җиләк, чәчкә эзләргә дә онытты. Карт башта дилбегәне селкеп, атка чөңгереп җибәрде, аннары кызчыкка күз генә ташлап алды да әйтте: «Я, белик, нинди сүзең бар икән?»,— диде. Раксана күзләрен зур ачып, кулларын селтәп, бер сулыштан әйтеп салды: «Минем әнием бар, ул мине килеп ала». Карт кызга текәп карап куйды, эндәшмәде. Сабыйның тууга ук ятим калуын, әнисенең үлүен, әтисенең кем булуы мәгълүм түгелен яхшы белә иде ул. Бабайның эндәшми торуын кызчык ошатмады: «Ие, инде, ие, минем әнием мине килеп ала, менә күрерсең!» — дип кабатлады. Карт авыр сулады. «Ярый, ярый, бик әйбәт. Тик син киткәч, мин нишләрмен икән соң? Кем белән басуга су илтермен?» — дигән булды. Раксана беразга аптырабрак калды. Бу турыда уйламаган иде әле ул. Хәер, сабыйлар өчен дөньяда хәл ителми торган каршылыклар юк. Раксана да бик тиз юлын тапты. «Әни сине дә үзе белән алып китәр, бергә китәрбез»,— дип, кулларын чәбәкләде.

Раксана үзенең хыялы, өмете белән бәхетле иде. Бервакыт ул әнисен төшендә күрде. Ул Талиянең әнисенә ошаган да, ошамаган да иде. Өстендә Фәридә апасыныкы кебек зәңгәр бизәкле күлмәк, чәчләре сап-сары, керфекләре Хисам бабай бүләк иткән курчакныкы кебек озын, үзләре еш-еш йомылып торалар. Әнисе Раксанага бер сүз дә әйтмәде, итәгенә утыртып сөйде генә. Чәченнән сыйпады, битеннән үпте. Әнисенең куллары йоп-йомшак иде, аның итәгендә утыру шундый да рәхәт. Раксананың мондый рәхәтне беркайчан да татыганы юк иде әле. Уянгач, ул як-ягына карап әнисен эзләде. Шундый татлы төштән аерылуы авыр иде аңа. Фәридә апасы, кызчыкның озак кузгалмый ятуын күреп, янына килде:

— Хәерле иртә, Раксана, хәерле иртә, яле, кем сикереп тора?!

Кызчык зур зәңгәр күзләрен тутырып тәрбиячегә карады һәм җитди итеп әйтеп салды:

— Мин әнинең нинди булганын беләм, ул йомшак, җылы була,— диде. Аннары үз-үзенә бик ышанып өстәде: — Ул мине барыбер килеп ала, менә күрерсез,— диде.

Тәрбияче кызчыкның чәченнән сыйпады...

БАЛА КҮҢЕЛЕ

ПАРЧА

Кичке аштан соң балалар шау-гөр килеп уйный башладылар. Озак та үтмәде, ике малайның нәрсә турындадыр кызып-кызып бәхәсләшкәннәре ишетелде. Тәрбияче апалары килеп җиткәнче уенчык машинаны тарткалап ватып та куйдылар.

Кулларына машина кисәкләре тоткан малайлар икесе дә башларын аска игәннәр.

— Машинаны кайсыгыз ватты? — дип сорады Гөлшат.

Шунда Азат исемле малай бик кыю кыяфәт белән:

— Марат ватты,— диде.

— Кем ваткан, шул төзәтә инде аны,— дип тәрбияче уенчыкны Маратка сузды.

— Мә, Марат, өегезгә алып кайт, әтиең белән бергәләп төзәтегез, ә иртәгә бакчага алып килерсең,— диде. Ләкин малай, алырга теләмичә, читкә үк китеп басты. Гөлшатның ачуы килде, ватуын ваткан, ә төзәтергә теләми, дип уйлады ул һәм машинаны көчләп малайга тоттырды. Шунда Марат яшь тулы зәңгәр күзләрен тутырып апасына карады да, үзәк өзгеч тавыш белән:

— Әтием юк минем! — дип кычкырды. Һәм уенчыкны идәнгә ташлап, елый-елый бүлмәдән чыгып йөгерде. Көтелмәгән бу хәлдән Гөлшат беравыкка югалып калды. Тынып калган балаларның куркынган карашларын тоеп, Гөлшат тиз генә үзен кулга алды һәм Марат артыннан ташланды.

Бакча ишек алды тып-тын, Марат беркайда да күренмәде. Кызның куркудан тыны кысылды һәм ул калтыранган тавыш белән:

— Ма-рат, Ма-а-р-а-т! — дип кычкырды. Нишләдем мин, нишләдем, дип уйлады Гөлшат. Кайсы якка йөгерергә белмичә басып торган кыз кинәт каен төбендә елаган тавыш ишетте. Марат агач төбенә сузылып яткан да, әрнүеннән учларына үләннәр йомарлап, сулкылдап елый иде.

Гөлшат әкрен генә малайны күтәреп алды һәм башын күкрәгенә кысып кочаклады. Маратка кушылып үзенең дә елый башлавын сизми дә калды кыз. Бу ике кешенең кайнар күз яшьләре — йөрәкнең бер үк сыкравыннан чыккан яшьләр иде. Чөнки Гөлшат үзе дә бит әтисез үсте. Кыз куллары белән йомшак кына итеп малайның күз яшьләрен сөртте.

— Гафу ит мине, Марат, гафу ит, энем, телисеңме, машинаны икәү төзәтәбез,— диде ул. Ярар, дигәндәй, малай сүзсез генә баш какты. Бераз тынычлана төшкәч, алар бүлмәгә керделәр. Ишек төбенә җыелган балалар аларның керәсен тын да алмый көтеп торалар иде. Гөлшат үзенең борчылганын балаларга сиздермәскә тырышып, кич буена уйнап-көлеп сөйләште. Бераздан алар икәүдән-икәү генә калдылар, гадәттә Маратны әнисе шулай соң ала иде. Ул килгәнче Гөлшат апасы белән ватык уенчыкны төзәттеләр, машинаның яңадан идәндә тәгәрәп йөргәнен күргәч, Марат салмак кына елмаеп куйды. Озакламый, арыган кыяфәттә Маратның әнисе дә килеп җитте. Бүгенге хәл турында Гөлшат бер сүз дә чыгармады, теләсә Марат үзе сөйләр дип, малайның үз ирегенә калдырды. Ана белән баланың сөйләшә-сөйләшә әкрен генә кайтып китүләрен кыз тәрәзәдән моңаеп карап калды.

Иртәгесен Марат бакчага башкаларга караганда иртәрәк килде. Аны күргәч, Гөлшат шатланып куйды, малайны ничектер иркәләп җылытасы килде кызның. Яшь тәрбияче көне буе читтән генә аны күзәтте, уйнап йөрсә дә, бала күңелендә ниндидер сүлпәнлек сизде ул.

Кичен алар мәйданчыкта шау-гөр килеп уйнадылар. Кояш бату ягына авышкач, бакча ишек алдында тавышлар да тына төште. Гөлшатның группасында бары тик ике бала гына калды. Алсу артыннан әтисе көн дә иртә килә иде, ә бүген нишләптер соңлады. Карап торуга бик бәхетле балалар сыман, ә бит менә икесенең дә бер яктан ятимлек. Маратны әтисе ташлаган булса, ә Алсуның узган ел әнисе авырып үлде. Менә шулай итеп кызның әнисе, ә малайның әтисе юк. Гөлшат аларны үз янына чакырып алды да:

— Әйдәгез, бергәләшеп гөлләргә су сибәбез,— дип, кечкенә савытлар тоттырды.

Күп тә үтмәде, бакча сукмагыннан Алсуның әтисе күренде. Кулында тулы сетка, күрәсең, ул эштән кайтышлый кибеткә кереп чыгарга да җитешкән. Кыз әтисенең каршысына йөгерде һәм, әтием! — дип аны кочып алды. Гөлшатның күзе чәчәкләр янында басып калган Маратка төште. Малай әтисе кочагына чумган кызга күзләрен тутырып карап тора иде.

Кулындагы савытыннан сандалиена су ага, ләкин ул аны сизми. Ә Алсу Маратны кызыктыргандай, әтисен чуп-чуп үбә, шаркылдап көлә. Марат кинәт бер-ике адым алга атлады да, борылып тәрбияче апасына карады. Нәрсә әйтергә дә белмичә торган Гөлшатның күзләрендә ул ниндидер ягымлы ризалык чаткылары күрде. Һәм кинәт йөгереп барып Алсуның әтисенә сарылды. Аптырап калган Илтөзәр үзе дә сизмәстән малайны кочаклап икенче тезенә утыртты. Сеткасыннан алып икесенә дә кып-кызыл алмалар тоттырды. Ул арада яннарына килеп баскан Гөлшат алмаларны юып та бирде.

— Әйдә, Марат, без синең әниең килгәнне көтәбез,— дип малайны үзе белән чакырды. Ләкин ул Илтөзәр абыйсының кулын тагын да кысыбрак тотты һәм апасына карап:

— Гөлшат апа, мин Алсулар белән кайтыйм әле, әниемне урамда көтәрмен,— диде.

Шунда ук Илтөзәр үзе дә сүзгә кушылды:

— Мөмкин булса, кайтсын безнең белән, без бит бер урамда торабыз. Бераз уйнагач, Алсу белән озатып куярбыз өенә,— диде.

Гөлшат белән хушлашкач, алар икесе ике яктан Илтөзәрне җитәкләп кайтырга борылдылар. Чатны узу белән каршыларына Маратның әнисе очрады. Марат исә әнисе янына килеп җиткәч тә кулын Илтөзәрдән ычкындырмады. Малаеның үз-үзен болай тотышыннан кыенсыраган әни кеше ихтыярсыздан алар белән рәттән атлады. Күп тә уйлап тормастан, Марат икенче кулы белән әнисен җитәкләп алды. Һәм алар әнә шулай дүртәү җитәкләшеп кайтып киттеләр. Куанышкан сабыйларның көлгән тавышлары алар киткән юлдан озак кына ишетелеп торды.

Зәлидә АКБИРОВА.



ЮЛЛАР ЧАКЫРА

Без сәяхәтләргә ни өчен чыгабыз?

Беренче булып сигез мең метр биеклекне буйсындырган альпинист Морис Эрцог кул һәм аяк бармакларын өшетә, аларны кисәргә мәҗбүр булалар. Үзенә кызганулы караш ташлаучыларга ул: «Минем нәрсә югалтканны бөтенесе күрә, әмманиләр тапканымны мин үзем генә беләм»,— дип җавап бирә.

Атаклы поляр тикшеренүче һәм сәяхәтче Ф. Нансен түбәндәгеләрне язып калдырган: «Һәр кеше торган җиреннән берничә чакрым гына читкәрәк китеп карасын әле. Ул үзе күрмәгән байтак нәрсә белән танышыр. Ә инде тагын да ераккарак китсә, көндәлек тормышындагы гади әйберләргә дә башка күз белән карар. Чит җирләрдә булу — тормышны ныграк белү өчен кирәк...»

Чыннан да, без сәяхәтләргә ни өчен чыгабыз соң? Берәүләрне ул физик яктан ныгыта, икенчеләргә кыюлык өсти, өченчеләрне максатчанрак итә, дүртенчеләргә һөнәр сайлауда булыша, бишенчеләргә табигатьне һәм үз-үзләрен аңларга ярдәм итә...

Соңгы вакытта аркаларына биштәр асып шәһәр читенә, урманга, елга буйларына сәяхәткә чыгучыларны көннән-көн күбрәк очратабыз. Галимнәр әйткәнчә, туризм — спорт һәм ялның кеше организмына иң файдалы төре.

Республикабызда җәмәгать эше тәртибендә эшләп килүче 30 га якын туристик клуб бар. Аларның иң билгеләләре: Казан дәүләт университетының география, туфрак-биология һәм геология факультетларында, педагогия һәм авиация институтларында, зур заводларда, Түбән Кама шәһәрендә, Брежневтагы 18 нче һәм Әлмәттәге 10 нчы мәктәп базасында оешкан туристик клублар. Алар сигез меңнән артык кешене берләштерәләр. Боларга җәйге каникул вакытларында сәяхәткә чыгучы укучыларны һәм ял көннәрен походларда үткәрүче меңнәрчә өлкәннәрне куша алабыз. Сәяхәткә чыгучылар арасында тулы гаиләләрне, күп кенә хатын-кызларны да күрү сөендерә.

Наил Шәрипов беренче тапкыр шундый турклубны, Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлаганнан соң, Түбән Кама шәһәрендәге 2 нче эшче-яшьләр мәктәбендә укытканда оештыра. Ә инде беренче чыныгуны ул институтта укыганда походларга йөреп алган була. Яшьләр бу клубка бик теләп йөриләр. Кама елгасы, туган як буйлап сәяхәтләр аларга тормышны тирәнрәк аңларга булыша. Алай гына да түгел, сәяхәтләр вакытында туган дуслык күпләр өчен мәхәббәткә дә әверелә. Чыннан да, походлар вакытында кешеләр бер-берсе белән якыннанрак танышалар, бер-берсе турында күбрәк беләләр бит. «Нефтехим» берләшмәсе хезмәткәре Зөлфия Шакирова белән шин заводында юрист-консультант булып эшләүче Әнәс Әхмәтгалиевне, музыка мәктәбендә укытучы Миләү-



Сез ничек ял итәсез?

ша Фәхретдинова белән шин заводы токаре Владимир Бабушкинны, укытучы Любовь Терехина белән Александр Шикуновны да әнә шундый походлар дуслаштыра, алар матур-матур гаиләләр коралар. Хәзер инде аларны сәяхәтләрдә уллары-кызлары белән бергә күрергә була.

Наил Хәбибрахманович та хатыны Нурия белән әнә шундый сәяхәт вакытында таныша. Алар да сәяхәтләргә икенче класста укучы Хәкимне һәм бишенчедә укучы Рөстәмне алып йөриләр.

Моннан алты ел элек Н. Шәрипов гаиләсе белән туган ягына, Әлмәткә күчеп кайта һәм 10 мәктәптә укыта башлый, класстан тыш эшләрне оештыручы була.

Укучылар белән танышуны ул походлардан башлый. Беркөнне сигезенче класслар янына керә дә: «Кемнәрнең нефтьне күргәне бар?» — дип сорый. Нефтьчеләр башкаласында яшәп тә нефтьне күрмәүчеләр байтак икән. Беренче поход «кара алтын» бирүче скважина янына бару була. Аннан соң мәктәптә югары класс укучыларын берләштергән РИТМ дип аталучы (русча романтиклар, эзләнүчеләр, уйлап табучылар, хыялыйлар дигән сүзләрдән) туристик клуб төзелә.

— Сәяхәтләрдә булучылар башкалардан гадәттә сабыр, авырлыкларга түзүчән булулары белән аерылып торалар,— дип сөйли Наил Хәбибрахманович.— Походлар аларда характер тәрбияли, дип әйтер идем. Бервакыт без кыш көне җиденчеләр белән Красноармейка дигән авылга барырга чыккач, буран кузгалып адаштык — дүрт сәгатьтән артык тукталыш урынын — «Яшьлек» пионерлагерен таба алмыйча йөрдек. Балалар ардылар, ашыйсылары килеп бетте. Минем кесәдәге ике кисәк ипине егерме биш кисәккә бүлеп ашадык. Шунда Рифат Шареев дигән малай: «Бервакытта да ипинең шулай тәмле икәнен белмәгәнмен. Ә бит мин моңа кадәр ипи телемен ашап бетермичә дә ташлый идем»,— дип әйтте. Моннан соң ул аны беркайчан да ташламаячак инде...

Укучылар һәр ял көне дип әйтерлек сәяхәткә чыгалар. Ә җәй көне — зур походлар. 1985 елда алар Агыйдел елгасы буйлап сәяхәт иткәннәр иде, ә узган җәйне Әлмәт-Брежнев-Алабуга-Танайка-Синтәк-Красный Ключ-Түбән Кама-Әлмәт маршруты буйлап йөргәннәр. Менә шундый сәяхәтләрдән соң мәктәпнең крайны өйрәнү музее яңа экспонатларга, ә укучылар күңеле истәлекләргә байый бара. Походлар турында күпләр мәктәпне тәмамлагач та сагынып искә алалар. Туристлар клубы советының элекке председателе Гүзәл Каюмова Мәскәүдә гидрология һәм мелиорация институтында укый, Роза Исхакова Ленинградта, геофизик булырга әзерләнә, Казан дәүләт университетында, педагогия институтында укучылар да байтак. Табигатькә, тарихка мәхәббәтне алар нәкъ менә сәяхәтләр вакытында алганнар. Клубка илебезнең төрле почмакларыннан килгән хатлар шул турыда сөйли.

Н. Х. Шәрипов походларга өлкәннәрне дә ала. Узган ел Уралга, Агыйдел елгасына үткәрелгән походта әнә Казаннан ирле-хатынлы Лилия һәм Виктор Симоновлар да катнашканнар.

Сәяхәтләр вакытында анда катнашучылар нинди хисләр кичерә? Сәяхәтчеләрнең бары берсен — Әлмәттәге 10 нчы мәктәп укучысы Лилия Әхмәтшинаны тыңлап карыйк:

— Походта йөрү җиңел түгел. Аркага авыр биштәр асып, көненә дистәләрчә чакрым ара үтү өчен күпме түземлелек, көч кирәк. Ә инде ялга туктап, учак янына тезелешеп утырып җырлап җибәргәннән соң бөтен арулар да бетеп китә. Походтан кайткач та андагы авырлыклар түгел, ә күңелле вакыйгалар гына искә төшә,— ди ул.

Үзләренең ял көннәрен, еллык ялларын сәяхәтләрдә үткәрүчеләрдән сорап карагыз, аларның берсе дә: «Үткән юлы бик күңелсез булды»,— дип зарланмас. Походка бер чыгып, юл йөрүнең романтикасы белән танышканнар юлга яңадан да җыеналар...

Атлас ГАФИЯТОВ.





ВӨҖДАН АВАЗЫ

ВӨҖДАН АВАЗЫ
ВӨҖДАН АВАЗЫ
ВӨҖДАН АВАЗЫ

Ул кайтканда вакыт соң, бик соң иде инде.

Илшат ишектән песи кебек кенә атлап керде. Аяк киемен салырга йокы бүлмәсенең утын яндырырга үрелде. Ләкин яктыдан курыккандай, бу уеннан кире кайтты. Кинәт аның күзенә тәрәзәдән ниндидер күләгә күренгәндәй булды. Ул куркудан каударланып юыну бүлмәсенә кереп бикләнүгә, су тавышы аралаш әнисенең эндәшкәне ишетелде.

— Улым, нигә бу хәтле соңга калдың?

Малай әнисенең ишек төбенә үк килеп җавап көтүен аңлады.

— Марсель белән фото ясадык.

Аның үз тавышы үзенә ят кебек тоелды. Тавышындагы үзгәрешне, улының дулкынлануын әнисе дә сизеп алды. «Димәк, фото ясамаганнар... Бүген барыбер әйтмәс». Әни кеше эченнән генә шундый нәтиҗә ясады да тагын караватына барып ятты.

Соңгы араларда Илшат әллә нишләде. Моңа кадәр бар серен әнисе белән уртаклаша торган малай аз сүзлегә әйләнде, тупасланды, араларына ниндидер салкынлык йөгергән кебек булды. Абыйсындагы мондый үзгәрешне сеңлесе Мәдинә дә чамалап йөри икән. «Әни, мине абый кинога ияртмәде. Малайлар белән барам, тагылма!» — диде дип, абыйсына булган үпкәсен аңа сөйләп бирде.

Рәхилә апа үзгәрешнең сәбәбен үзенчә эзләде.

Балалар әтисез үсте. Кимсенмәсеннәр, башкалар янында ким булмасыннар, дип тырышты бит. Велосипедын алып бирде, фотоаппаратын. Ял көннәрен балалары белән үткәрергә тырышты. Кинога барды, алар белән чаңгыда йөрде. Күңелләренә гел әйбәт сыйфатлар гына салырга тырышкан иде ләбаса.

Гаиләдә киңәш-салым аласы буламы, берәр җиргә барырга туры киләме — алар белән киңәште, уртага салып сөйләште. Менә хәзер генә нәрсә булды соң аның улына? «Әллә берәрсенә күзе төште микән,— дип уйлап алды Рәхилә апа.— Бәлки, күңелендәге яңа хисләрне яшерергә тырышудан эченә бикләнгәндер. Бәлки, ул бүген дә аның белән очрашкандыр?..»

Улы юыну бүлмәсеннән чыккач, әнисе йомшак кына эндәште.

— Ашны суыткычка куйган идем, җылытып аша.

Илшатта аш кайгысы түгел иде.

Ул тиз-тиз генә чишенеп, яту ягын карады. Юрганын башыннан ук томалап, күзләрен чытырдатып йомды. Әйтерсең, шушы караңгылык аны урамда калган ямьсез хәлләрдән яшереп алып кала. Әйтерсең, аны моннан берәү дә табып ала алмаячак...

...Алар паркта очраштылар.

— О, новичок та килгән. Молодец!

Классташы Ләйсәннең Илшатны сәламләве иде бу. Кызлар өчен Марсель үз кеше. Беренче класстан алып бергә укыйлар. Илшат яңа әле, сыналмаган. Быел җәй гаиләләре яңа фатирга күчеп килделәр. Хәзер Илшат алар белән бер класста укый. Бүген менә дәрестән соң паркка чыгарга сүз куешканнар иде.

Каш-керфекләрен күзгә бәрелеп торырдай итеп чем-карага буяган Ләйсәнне дә, чәчен малайларча кыска итеп калдырган Светаны да Илшат беренче көннән үк истә калдырды. Ә кызларның Эльза исемлесен Илшат ни өчендер үз күрде. Ләйсән белән Света башкалардан аерылып торырга телиләр. Хәер, Светасы яхшы укый, сәләтле кыз.

Ләйсәне башкачарак. Әйбәт киенә. Чалбар, кофта, туфли дисеңме, һәммәсе күзгә бәрелеп тора.

Бүген Эльза да алар белән бөтерелә. Өстендә мәктәп формасы. Кер кунарга да өлгермәгән ап-ак яка, ак алъяпкыч. Чәчләрен җыеп зәңгәрсу тасма белән бәйләгән.

— Күрәсезме, тегендә Сәгыйтова түгелме соң?

— Нәкъ үзе!

— Каршыларына чыгабызмы? — Эльза аптырап Ләйсәнгә карады.

— Ни өчен?

— Ни өченме? — дип тезеп китте Ләйсән.— Чөнки синең безнең белән дуслашуыңа Сәгыйтова шартларга җитешкән.

Эльза әле Светага, әле Ләйсәнгә карап алды.

— Миңа ышанмасаң, әнә, Светадан сора.

— Әйе,— дип өстәде тегесе.— Химичкага сөйләгән.

— Гайбәтче ич ул,— дип куәтләде Ләйсән.— Минем турыда ни генә сөйләп бетермәде.

— Нинди әшәкелек,— дип мыгырданды Эльза.— Әйтәм аңы контроль эшен күчертмәгән булды.

Парк сукмагы аларны өрәңге яфраклары җыеп йөргән Гөлназ Сәгыйтова белән Миләүшә Камалова янына алып чыкты.

— Менә очраштык та...

Ләйсән, Света, Эльза кызларны әйләндереп алдылар. Марсель белән Илшат аларның җан сакчысыдай арткарак басты.

Гөлназ белән Миләүшә болар белән сүзгә кермичә генә китмәкчеләр иде дә, шулчак Ләйсән Гөлназның тезенә төртеп җибәрде. Кыз егылды. Кулындагы яфраклары җиргә чәчелде.

— Син нәрсә! Тиле бәрән орлыгы ашадың мәллә?!

Үзләрен әйләндереп алган боҗраны Эльза турысыннан өзеп, Миләүшә китәргә талпынды. Шуны гына көткән кебек, кемдер аны төртеп җибәрде.

Ике кыз өстенә пычрак, мыскыллы сүзләр яуды. Пөхтә киемнәре таушалды...

Марсель белән Илшат кызларга тырнак белән дә кагылмадылар. Алар Ләйсәннәрнең һәр хәрәкәтен сүзсез генә читтән карап тордылар... Мондый тамашаны шушылай битараф карап тору үзе үк түбәнлек, хәтта, җинаять булуын Илшат белә иде ләбаса! Белде, аңлады, әмма үзендә шушы әшәкелекне туктатырлык көч тапмады. Явызлык каршысына басып, намусны яклардык көч тапмады.

Илшат яңа классташлары турындагы бар белгәннәрен исенә төшерергә тырышты. Болай карап торышка Марсель дә начар малай түгел шикелле. Фото белән шөгыльләнә. Рәсем ясарга ярата. Илшатка үзе ясаган табигать күренешләрен күрсәтте. Нигә болай килеп чыкты соң әле? Үзе дә яхшылык белән яманлыкны аера белә кебек иде ич.

«Эльза, Эльза...— дип пышылдады малай.— Бу хакта үзең ниләр уйлыйсың икән? Әгәр паркта син булмасаң, мин анда бара идемме соң?»

Илшатның тыйнаксыз кызлар турында ишеткәне бар. Әмма менә классташ кызларының шундый булуын көтмәгән иде. «Эльза аларга нишләп иярде икән? Хәер, нишләп әле Эльза гына,— дип каршы төште ул үз-үзенә. мин дә иярдем ич, Марсель дә...»

Әйләнә-тулгана ята торгач, Илшат йокыга китте. Йоклаган чагында да әлеге вакыйга аңа тынгылык бирмәде. Ул саташты. Кайдандыр үзәк өзгеч тавыш белән кычкыра-кычкыра сеңлесе Мәдинә килеп чыкты. Өстендә ап-ак күлмәк, чәчендә — ап-ак ефәк тасма. Ләйсән, Света, Эльза аны җан-фарманга куалар, әшәке сүзләр кычкыралар. Мәдинә: «Ил-ша-аат!» — дип өзгәләнә. Әмма Илшат урыныннан да кузгала алмый, нидер әйтмәкче була — тавышы чыкмый.

Ул салкын тиргә батып уянып китте. Тәрәзәне каплап бетермәгән пәрдә читеннән таң кызыллыгы йөгергән офык күренә. Таң ата. Дөнья яктырганнан яктыра, күк йөзе зәңгәрләнә. Илшатның карашы еракка, таң яктылыгына төбәлде. Ләкин бүгенге таң Илшат өчен матур көн алып килмәячәк. Ни йөзе белән мәктәпкә барыр ул. Хәер, мәктәпкә хәтле башын түбән иеп тә барган булыр иде. Тик менә класска ничек килеп керер? Гөлназ белән Миләүшәгә ничек итеп күтәрелеп карар?

Илшатның миен мең төрле уй, мең төрле сорау каезлады. Кайсы гына сорауга юлыкса да, малай үз-үзен күралмады. Гаебенең зурлыгын йөрәгенең иң нечкә кылы белән тойды. Шул гаепнең авырлыгын күтәргән хәлендә аннан котылу чараларын таба алмыйча гаҗизләнде.

Бераздан әнисе торды. Табада май эрегән тавыш ишетелде. Өйгә тәмле ис таралды. Илшат урыныннан да кузгалырга кыймыйча тып-тын ятты.

Ниһаять, әнисе иплəп кенә аның иңенә кагылды.

— Улым, тор инде. Төне буе саташтың, авырыйсыңмы әллә?

Ул эндәшмәде. Менә хәзер сикереп торасы иде дә, әнисенең кочагына ятып бәйнә-бәйнә сөйләп бирәсе иде. Әнисе аңламый калмас, аңлар иде. Ачуланса да үпкәләмәс иде. Тик ничек итеп аңа сөйлисе соң?

— Улы-ымм! — дип сузды Рәхилә апа.— Әйдә, соңга калма!

Илшат әкрен генә юрганын ачты, торып утырды һәм башын аска иде. Күңелендәге бар борчуларын шушы минутта, менә хәзер үк әнисенә сөйләргә тиешлегенә төшенде.

Бу — аның вөҗдан авазы иде.

С. ЗАКИРОВА.
Казан шәһәре.

КЕМ РӘНҖЕТТЕ?

ФЕЛЬЕТОН

«...Сәламәтлеге беткән әниемнең ягарга утыны да булмагач, кышларын үзебезгә алып килеп тордык...» Брежнев шәһәрендә яшәүче Нәфисә Галиәхмәтованың хаты шушы рәвешчә авыр, сагышлы көй сыман дәвам итә. Гәрәбәдәй түгәрәк хәрефләрдән тезелгән моңлы бу хатның озынлыгы җиде биттән артып китә.

Аның әнисе Фатыйма апа Ахунова күргән газаплар, рәнҗетелүләр турында укыгач, ирексездән күзеңә яшьләр килә. Барысына да каты бәгырьле Сәмәкәй авыл Советы председателе һәм шушы ук авыл Советы секретаре гаепле икән. Аларның кыланышлары белән танышканда, йодрыклар үзләреннән-үзләре йомарлана. Олы кешене шушылай кимсетүләренә, закон бозуларына ничек итеп юл куймак кирәк!?

Фатыйма апа шушы Сәмәкәйдә туып-үскән, буй җиткәч киявгә чыккан, балалар үстергән. Гомере буе туган колхозында тир түккән. Менә шулай балаларны үстереп, кошлар сыман очыртып бетергәч, берданбер көнне үзен начар хис иткәндәй була. Һәм шәһәргә, кызы янына күченергә исәп тота. Озын-озак уйлап тормастан, пропискадан төшә дә, йорт-җирен авыл Советы карамагына тапшырып, Фатыйма апа китеп тә бара. Көн артыннан көн үтә һәм матур яз килеп җитә. Шул чакны Фатыйма апага тагын әлләни була, аның күзенә шәһәрнең бар җире күңелсез булып күренә башлый. Авылда калган өе төшләренә кереп йөдәтә башлый. Авыл урамындагы кое сиртмәсенең шыгырдауларына кадәр колагына ишетелә кебек тоела. «Җитте, балалар,— ди ул бер көнне кияве белән кызына.— Мине Сәмәкәйгә кире кайтарыгыз!».

Әбекәйнең төенчекләрен төягән «Жигули» Сәмәкәйгә таба элдерткән.

Авыл Советындагыларның «кешелексезлекләре» нәкъ менә Фатыйма апа кире авылга кайткан көннән башлана да инде.

... Хуҗалар кайтып, тәрәзәгә кадакланган такталарны ачсалар, ни күзләре белән күрсеннәр — электр чыбыклары өзелгән. Өйдә ут юк! Өйгә электр чыбыкларын кабат тоташтыру өчен Фатыйма апаның кызы Нәфисәгә район прокурорына кадәр барып җитәргә туры килә...

Көннәр җылынгач, бакча эше кузгала. Колхозчыларның бакчасын колхоз сөрдерә. Халык бәрәңгесен, суганын утырту эшенә керешә. Фатыйма апаның бакчасы гына сөрелмәгән килеш ята. «Улым, минем бакчамны калдырма инде!» — дип карчык тракторчы егет каршына чыга. Әмма егет җавапны кыска тота: «Авыл Советы секретаре сезнең бакчага кермәскә кушты. Югыйсә, штраф түлисең дип әйтте»,— ди.

Фатыйма апакайның күрәселәре болар белән генә бетмәгән икән әле. Авыл Советы аны кире пропискага алудан катгый рәвештә баш тарта. Менә сиңа, мә! Хәбәрнең монысы Нәфисәне өнсез итә.

«Кимсетелгән, кагылган кешенең кайгысы кемгә кирәк соң бу дөньяда?» — дип уйлый Нәфисә һәм редакциядән журналист төшәсен башына да китерми. Әле яңа гына алган өч бүлмәле иркен квартирдан закон бозучыларны хатлар аша камчылыймы камчылый. Ни әйтерең бар, әйбәт яшиләр. Үзе кранчы, ире җылылык челтәрендә эшли икән.

Галиәхмәтовлар белән танышкач, хәбәрче Тукай районының халык депутатлары Советы башкарма комитеты председателе Владимир Николаевич Борисов янына сугыла. Аның ни йомыш белән йөрүен белгәч, председатель сискәнеп үк китә. Нидер әйтергә, аңлатырга теләгәндәй авызын бер ача, бер яба, тик эндәшә алмый интегә. «Әйдәгез Сәмәкәйгә барыйк, ничек итеп закон бозулары урында ансатрак ачылыр»,— ди ул, ниһаять.

Авыл Советына килеп кергәч, инде хәбәрче үзе сүз табалмый аптырый. Ник дисәң, авыл Советы председателе Илдус Закиров та, секретарь Гөлчирә Вәлиева да бик күркәм кешеләр икән ләбаса. Нәфисә ханым хатында тасвирланганча бер дә алай мәрхәмәтсез, закон бозучыларга һич кенә дә ошамаганнар. Илдус Закиров — япь-яшь, ачык йөзле кеше икән. Ялгызак карчыкны кимсетә алыр, дип һич кенә дә әйтә торган түгел. Гөлчирә Вәлиева турында яман сүз әйтү бөтенләй дә килешмәс. Нәфисәнең редакциягә җибәргән җиде битле хатын укыганны бүлдермичә, сабыр гына тыңлап тордылар. Юк, юк, хәбәрче алай беренче тәэсирдән генә эреп китә торганнардан түгел. Казан тиклем Казаннан килгән икән, хезмәт ветеранын кимсетергә, җитәкчеләрнең башбаштаклыгына юл куймас!..

Алай да сөйләшә-аңлаша башлагач, хат авторының башкалар күзеннән яшереп куйган җеп очы кинәт кенә күренә башлый...

Нәфисәләрнең менә-менә яңа фатир алыр чаклары җиткән имеш. Гаиләгә фатирның өч бүлмәлесен болай да бирәселәр икән бирүен. «Булгач-булгач, нишләп әле өч кенә бүлмәле! — дип фикер йөртә Нәфисә.— Дүрт бүлмәле кирәк!» Шушы ният белән карт әнисенең йорт-җире, аның тормышы белән исәпләшеп тормастан, Фатыйма апаны шәһәр кешесе итә дә куя! Бу эшләрнең хаклыгын раслап, Брежнев шәһәрендәге торак-коммуналь бүлегендә мөһере сугылган язу ята. Анда акка кара белән: «Иптәш Ахунованың авылда йорты-җире юк»,— дип язылган. Тик менә, фатир бүлгәндә, Галиәхмәтовларга барыбер өч бүлмәле генә квартира тия. Аларның аллы-гөлле планнары былтыргы кар шикелле эреп юкка чыга, тормышта бары чынбарлык кына кала. Чынбарлыкта исә яңа фатирда Фатыйма апаның артыклыгы сизелә башлый.

Хуҗасыз йортлардан электр чыбыклары өзелә, билгеле. Аннары кинәт кенә авылга кайтып төшкән шәһәр кешесен пропискага алу да ансат кына түгел икән шул! Фатыйма апа яңа алынган квартирның ордерына кертелгән ләбаса!

Җир участогы мәсьәләсен дә Галиәхмәтовлар киң һәм колачлы уйлаганнар. Бар икән баш үзләрендә! Авылдагы йорт-җир менә дигән дача ич! Ара якын, машина бар, дигәндәй...

— Хәзер инде кемнең кешелекле, кемнең кешелексез икәнлеген үзегез уйлап карагыз,— ди Гөлчирә Вәлиева.— Үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып, әниләренең оясын туздырып алып киткән балалармы, әллә башкалармы? Андый гаилә бер безнең Сәмәкәйдә генә дә өчәү. Ул әбиләрне я алып китәләр, я алып кайталар. Анныры шул ук балалар, безнең әниләргә авыл Советы ярдәм итми дип, шикаятьләр яза башлыйлар.

Әнә шундый балаларның мәрхәмәтсезлеге, каты бәгырьле булуы Гөлчирә Вәлиеваның күңеленә барып тигән дә.

— Кире кайттым шул инде,— ди Фатыйма апа.— Дүрт бүлмәле квартир булмагач, нишләмәк кирәк?!

«...Дөреслек бар икән ул үзе! Аны эзли белеп эзләргә генә кирәк икән! Әниебезнең үз йорты булгач, шул авылда эшләп, шул колхоздан лаеклы ялга пенсиягә чыккач, ул үзе теләгән вакытта кайтып тора ала һәм бакчасыннан файдалана ала икән!» — дип яза иптәш Галиәхмәтова.

Соң, Нәфисә ханым, пенсиядәге әниегезне салкын кыш көннәре үзегездә тотып, җәй көннәрне кире үз өенә кайтарасыз икән, әлбәттә, моңа берәү дә, беркайчан да каршы түгел. Тик аны «Авылда йорты-җире юк»,— дигән мөһерле язусыз гына алып китегез. Югыйсә, үзегез югалткан дөреслекне кабат башкалардан таптырырга керешүегез бар.

Равил ХАҖИЕВ.

«ИҢ ЯКЫН КЕШЕБЕЗ УЛ»

Хат ташучы. Кешенең хис-шатлыкларын, моң-сагышларын сыйдырган ул китергән кош теледәй хат безнең күңелләргә ямь өсти, йөрәкләрне дәртләндерә. «Сандугач сурәте төшкән минем күлмәккәемә; хатың килсә, яллар була минем йөрәккәемә»,— дип сагынып, сагышланып хат көтүче әбиләребез нинди генә кыен заманнарда да аның өчен сөенчегә бүләк әзерләп куйганнар. Бүгенге тыныч, иркен тормышта да без аларны һәркөн диярлек яшерен бер өмет, дулкынлану белән көтәбез. Алар белән безнең өйләргә әллә никадәр матбугат яңалыклары — әле буяу исе дә бетеп җитмәгән газета-журналлар, сөйгән ярларның мәхәббәттә аңлашуы, туган йортын калдырып киткән балаларның ата-анасына сагынычлы сәламе, туганнар, халыклар арасындагы дуслык хисләре килә.

Хәбәрләрнең шатлыклысы булсын, кайгылысы булсын — аларны беренче уртаклашучы да, юатучы кешебез дә ул безнең.

Аның эше бик мәшәкатьле һәм күптөрле. Ярдәмгә мохтаҗ ялгыз әбибабайлар өчен киңәшче дә, ярдәмче дә. Элемтә бүлегеннән ераграк урнашкан авыл халкының телеграмма сугу, посылка салу кебек йомышларын да үти ул. Гомумән, почта хезмәткәрләренең игелекле ярдәменнән башка безнең бер генә көнебез дә үтми. Менә шуңадыр, Матбугат көне бәйрәме якынлашыр алдыннан редакция хат ташучыларны котлаган, җылы рәхмәт сүзләре тулы хатларны күп алды. Һәрбер хатта диярлек «шатлык өләшүче», «бәхет китерүче» дип атаганнар аларны. Иң тырыш хезмәт алдынгылары, үрнәк кешеләр турында ул хатлар.

«Алар көн дә почта бүлекчәсеннән, иңнәренә газета-журналлар тулы сумкаларын асып, юлга чыгалар. Менә арадан берсе — Галия Бәһаветдинова — безнең Фрунзе урамына борыла. Аны күрүгә кешеләрнең йөзләре яктырып китә. Һәр йортта көтеп алалар, рәхмәт әйтеп озатып калалар аны»,— дип яза Баулы эшчеләр поселогыннан Габдулла Хәлимов Галия Бәһаветдинованың хезмәт коллективында да олы ихтирам казануы, аның рәсеме бик лаек рәвештә Мактау тактасында торуы, Галия ханымның хезмәттәшләре Наилә Булатова, Сания Авзалова, Нәзифә Барсуковаларның да үз эшләрен шулай ук тырышып, намус белән башкарулары турында.

Җиңелдән түгел хат ташучы хезмәте. Кышкы бураннарда да, көзге пычракларда да, җәйге челләдә дә ул һәрвакыт юлда, син көткән хәбәрне вакытында китереп җиткерү өчен ашыга.

«Терекөмеш баганасы 45 градус эссене күрсәтә. Ә ул, кулына зур сумкасын тоткан җитез ханым, киң урамнар буйлап атлый.

— Нигә көн сүрелгәнне көтмисең? — диләр аңа. Мәгъфирә апа Сабирова елмая гына:

— Солдат хатларын ничек итеп кичкә кадәр өләшми түзмәк кирәк! Тизрәк әниләрен сөендерим дим.

Еллык газета-журналларга язылу бездә мамык җыю чорына туры килә. Һәркем кырда. Шуңа карамастан, безнең участокта бер генә гаилә дә газета-журналларга язылмыйча калмый. Барысы да аның тырышлыгы аркасында. Хөкүмәтебез Мәгъфирә апаның хезмәтен медальләр, кыйммәтле бүләкләр белән бәяләде. Без дә яраткан журналыбыз аша аңа күп рәхмәтебезне белдерәбез»,— дип язганнар безгә Ташкент өлкәсенең Коммунистик районы, «Ленин юлы» колхозыннан Ф. Гәрәева, Т. Исмадиярова, С. Миңлебаева, Л. Нагай иптәшләр.

Күңел җылысы белән әретелгән хатларны укыйсың да уйга каласың. Кешеләр күңелендә башкаларга карата рәхмәт хисләре кайчан яулана? Үз хезмәтенең кешеләргә кирәклеген бөтен йөрәге белән тоеп, аны мәхәббәт белән башкарганда гына кеше әнә шул олы рәхмәткә лаек була. Шундыйларның берсе — гаиләдә үрнәк хатын, ана, игътибарлы иптәш, уңган почтальон Нәзилә Ибраһимова турында Саба районы, Олы Саурыш авылыннан Роза Әскәрева хәбәр итә:

«Егерме сигез ел буена көн дә 4 чакрым арадан почта алып кайта. Үз эшен яратып, намус белән башкара. Якты йөзе, тәмле сүзе белән һәркем күңеленә ачкыч таба белә. Иптәше — колхозның алдынгы шоферы — Фәиз абый белән яшьләргә үрнәк булып матур гомер итәләр»,— ди ул.

«Безнең илебездә көн саен меңләгән тираж белән газета-журналлар чыга. Аларны һәр гаиләгә изге күңелле хат ташучылар китерә бит. Шуларның берсе — 126 нчы почта бүлекчәсеннән Айсылу Нигъмәтуллина. Без, пенсионерлар, өч бала һәм авыру ирен тәрбия итүче бу ханымның күңел җылысын тоеп яшибез»,— дип тәмамлаган үзенең рәхмәт хисе тулы хатын Казаннан Гыйльметдинова.

Мәүлидә Садриева да хатында почта хезмәткәрләренең халык арасында ихтирам казануының сәбәбен аларның кешеләргә карата игътибарлы, кайгыртучан булуыннан күрә. *«Мин 70 яшьлек гомеремнең 35 елын Казанда яшәдем. Тормышның авырлыгын да, шатлыгын да кичердем. Кешегә боларны ялгыз кичерүе бик авыр. Шушы еллар эчендә Бауман урамындагы 84 нче почта бүлекчәсе минем өчен туган йортым кебек булды. Анда озак еллар тырышып эшләүче операторлар Миңҗиһан Әхмәрева, Антонина Григорьева, Анна Карпова, Клавдия Баннова, Надежда Гришина; почтальоннар Суфия Гобәйдуллина, Галина Иванова, бүлекчә мөдире Валентина Егоровалар минем һәм минем кебек башкалар өчен чын сердәш, туганга әйләнделәр. Нинди генә йомыш белән килсәң дә, алар һәрвакыт игътибарлы, ярдәмчел, ягымлы»*,— дип рәхмәтен юллый һәм бәйрәм белән котлый ул аларны.

«Иң якын кешебез ул безнең. Яшьләргә акыллы киңәшен әйтер, олыларга ягымлы җылы сүзен кызганмас. Өч бала анасы булуга карамастан, һәр эшкә өлгерә. Берәрсенә котлау җибәргәндә яисә газета-журналларга язылганда кыенлык очрыймы — һәркемгә ярдәм итә,— дип язалар Азнакай районы, Сәпәй авылы кызлары Хәсәнова, Миргасыймова, Гәрәева, Исламова һәм башкалар Мәрьям апа Хөсәенова турында.— Без хәзер төрлебез төрле шәһәрләрдә укыйбыз. Туган авылыбызга хат язарга утырсак, Мәрьям апабыз күз алдына килеп баса. Ул һәрвакыт шулай шат күңелле булсын һәм тагын озак еллар буе кешеләргә изге хәбәрләр таратсын иде».

Елның иң матур вакытында, табигатьнең яңа гына йомшак хәтфәдәй яшеллеккә күмелгән чагында илебез Матбугат көне бәйрәмен үткәрә. Илдән илгә, өйдән-өйгә берөзлексез котлаулар агыла. Иңенә сумкасын аскан хат ташучы йөзендә аеруча горур елмаю балкый ул көнне. Чөнки кешеләргә сөенеч китерүдән дә зур бәхет юк дөньяда.

Тик дөньялар гына тыныч, имин булсын. Таңнар тыныч атса гына җир йөзен матур гөлләр күмәр, үзәкләрне өзеп, хыялларга күмеп, сандугачлар сайрар, кешеләр бер-берсенә изге, куанычлы хәбәрләр генә юллар.

Нәүбаһар БАДЫКОВА.



Кадерле редакция!

Мин Чистайда күп еллар яшәп, җыештыручы булып эшләп лаеклы ялга чыктым. Ялда булсам да эшемне дәвам иттерәм. Коммунистлар партиясе, совет хөкүмәте дөньяда тынычлык булсын өчен, хезмәт кешесе рәхәтләнеп эшләсен, ял итсен өчен тырыша. Мин, сугыш ветераны әтием Зиннур Зәһидуллин, әнием Хәят Зәһидуллиналар исеменнән, газиз Ватаныбызның муллыгына, матурлыгына куанып, партиябезгә олы рәхмәтебезне җиткерәм.

Илебезнең тынычлыгын саклап каннарын койган батырларыбызны бик еш искә алып сөйләшәбез. Сугышлар гына була күрмәсен, имин яшик дип телибез.

Әкълимә **МӨХӘММӘТШИНА.**





— Кадерлем! 1987 елдан алып 1997 елгача булачак туган көннәреңнең барчасы белән берьюлы котлыйм сине!

А. ХӘСӘНОВА *рәсемнәре.*

ӘТИ-ӘНИ КЕБЕК БУЛДЫЛАР

Безнең әниебез яшьли вафат булган. Сугыш башлануга, әтиебез дә фронтка китә һәм кире әйләнеп кайтмый. Апабыз Розага бу вакытларда 17–18 яшь, шәһәрдә, фатирда яшәгән була. Әти сугышка киткәч, ул безне дә үз янына алдырды. Яшь булса да, безне ташламады, барыбызны да үстереп, тормыш корырга ярдәм итте. Без дә апаны тыңладык, аның сүзеннән чыкмый идек. Иң кече сеңелебезне апа кияүгә чыкканда үзе белән ияртеп алып барды. Җизнәбез Мөхәммәт Дәүләтшин да сугышта булып кайткан кеше иде. Бик шәфкатьле булып чыкты. Безнең өчен әти-әни кебек булдылар алар. Апа белән җизнигә журнал аша рәхмәтебезне җиткерсәгез иде. Аларның картлыгы тыныч, матур, тигез килсен, сугышлар кабатланмасын, ятимнәр булмасын иде.

Туганнары Әминә,
Гөлфия һәм Галимҗан.
Казан шәһәре.



Сүзсез.

Хөрмәтле редакция!

Мин беренче мәртәбә генә язам. Моңа «Ирекле уеннарга» чакырылган Саманта Смитның әнисен телевизордан күрү сәбәп булды. Ул ачы хәсрәт аша безгә карап елмая. Ана өчен бала югалтудан да ачы кайгы булмас, билгеле. Ә Саманта үзенең якты елмаюы белән безнең күңелләрдә калды. Ул әле хәзер дә шулай елмаеп безнең илебез турында сөйлидер кебек. Нәкъ менә Саманта кебек кыю кызлар күп булсалар, Америкада илебез турында күбрәк белерләр иде.

Бу көннәрдә кем генә киләчәк турында уйланмас икән? Җир йөзендә яшәү өчен, тыныч киләчәк өчен кискен көрәш бара. Ә киләчәк безнең барыбыз өчен дә кирәк. Язгы ташкыннары, тамчылары белән язлар, тургай моңы белән җәйләр, мул уңышлы көзләр һәм үзенең аклыгы, сафлыгы белән кышлар киләчәктә дә булырмы дип ирексездән уйлап куясың. Яшәп туймас гүзәл җиребезгә куркыныч янамасын. Азат тормышыбыз өчен гомерләрен биргән батыр солдатларыбыз тыныч йокласын, аналар балаларының киләчәге өчен борчылмасын иде.

Кеше космосны өйрәнә, атомны тыныч хезмәттә куллана. Кеше акылы көннән-көн, яңадан-яңа ачышлар ясаган елларда дөньяга куркыныч яный. Җир өстенә көннән-көн үлем уты арта. Азмы инде мин күргән үлемнәр, миңа сеңгән каннар һәм кайнар яшьләр, дип җир сыкрый кебек.

Америка укучысы Саманта, кечкенә булуына карамастан, кыю адым ясады. Киләчәкнең тыныч, аяз булуы өчен тырышуы иде аның. Аның исемендә бакчаларда гөлләр кояшка үрелде. Яшь әниләр нәни сабыйларына аның исемен куштылар. Яңа йолдыз аның исемен алып күктә балкып нур сибә. Бу гаҗәп түгел. Чөнки аның фаҗигале язмышы безнең барыбызны дулкынландырды. Саманта әле яшәргә, шатланырга, хыялларын тормышка ашырырга, тормыш гөле булып чәчәк атарга тиеш иде. Җир йөзендә бер генә бала да сугыш афәтен күрергә тиеш түгел. Без, аналар, шуны телибез.

Сәвия **ЛОТФУЛЛИНА.**
Әлмәт районы.



— Бер матур истәлек булсын әле.

БӘЛКИ, ЯРДӘМ ИТӘРСЕЗ?

Мин үзем Биектау районының Сосмак авылында тудым. Мин кечкенә вакытта ук әнием вафат булды. Әтием икенче хатынга өйләнде. Без үги әни белән яши башладык. Аның да ияртеп килгән Ренат исемле малае бар иде. Үги әни минем өчен бик әйбәт булды, әмма аны әти бик җәберләде. Аннары мине балалар йортына урнаштырдылар. Шуннан соң әти үги әнине куып җибәргән. Бу 1959 еллар иде. Үги әниемнең исеме Миңнура, фамилиясе Юсупова, аның әтидән туган бер кызы да булырга тиеш. Мин аларны инде берничә тапкыр эзләтеп карадым, әмма таба алмадым. Бәлки, миңа журнал укучылар ярдәм итәр?

Әхәт **ИДРИСОВ.**
Казан шәһәре.



— Культура дәрәҗәмне күтәрергә ирек бирмисең!

В. ВАСИЛЬЕВ *рәсемнәре.*

Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!



Айлык иҗтимагый-политик һәм әдәби-нәфис журнал. 1926 елда чыга башлады.

Бу санда:

Тәэминә Биктимерова. *«Таң кызы», 4 бит.*
Разия Тимерханова. *«Бәхет турында уйлану», 5 бит.*
Илсөяр Хәйруллина. *«Мәскәүдән кайткач», 6 бит.*
З. Бадыйкшанова. *«Хезмәттә яуланган хөрмәт», 8 бит.*
Яңа җыр, *10 бит.*
Илдар Юзеев. *«Гашыйклар тавы», повесть-поэма, 11 бит.*
Гөлфия Юнусова. *Шигырьләр, 15 бит.*
Роза Хафизова. *«Әни нинди була?», хикәя, 16 бит.*
Зәлидә Акбирова. *«Бала күңеле», парча, 17 бит.*
Атлас Гафиятов. *«Юллар чакыра», 18 бит.*
С. Закирова. *«Вөҗдан авазы», 20 бит.*
Равил Хажиев. *«Кем рәнҗетте?», фельетон, 21 бит.*

Тышлыкның беренче битендә:

«Алмагачлар чәчәк атканда».

Р. МӨХӘММӘТҖАНОВ *фотосы.*

Баш редактор — В. Ф. ИХСАНОВА. Редколлегия: Д. С. ДӘҮЛӘТШИНА, Н. З. ЗАКИРОВА, Д. Х. ЗАРИПОВА, И. И. ИЛЯЛОВА, М. Ә. ӘМИРХАНОВ (баш редактор урынбасары), М. Г. МАЛИКОВА (җаваплы секретарь), Ә. Ш. МУСИНА, М. А. СӘЙДӘШЕВА, И. Г. СУНКИШЕВА, Г. Ш. ШӘРӘФЕТДИНОВ, И. Г. ЮЗЕЕВ.

Художество редакторы — З. МӨХӘММӘТҖАНОВА. Техник редактор — Э. ӘДИАТУЛЛИНА.

Общественно-политический и литературно-художественный журнал «Азат хатын» («Освобожденная женщина») на татарском языке.

Безнең адрес: 420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2, редакция журнала «Азат хатын».

Телефоннар: хатлар һәм авыл хуҗалыгы бүлекләре — 53-07-46; промышленность, пропаганда, сәнгать бүлекләре — 53-07-44; художество редакторы — 53-07-42; баш редактор урынбасары һәм җаваплы секретарь — 53-57-69; кабул итү бүлмәсе — 53-07-40; баш редактор — 53-38-75.

Производствога биреде: 9.03.87. Басарга кул куелды 6.04.87. Заказ М-88 ПФ 05112. Тираж 406744 Кәгазь форматы 60×90. Күләме 3 басма табак + өстәмә битләр 1 табак. КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2.





ТӨСЛӘР ОСТАСЫ

Хәнәфи Афзал улы Нафиков — театр рәссамы, ул композитор Нәҗип Җиһановның Муса Җәлил һәм Нәкый Исәнбәт либреттоларына язган «Алтынчәч», «Түләк һәм Сусылу» операларына, Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балетына, «Мария Стюарт» һәм «Гроза» спектакльләренә декорация эскизлары эшли. Риза Ишморатның «Тормыш дулкыннары», Илдар Юзеевның «Командировка», Мөхәммәт Мәһдиевнең «Борчулы өч көн», Роберт Батулланың «Баһадирлар» исемле әсәрләренә декорацияләр ясап, сәхнәгә куюда катнаша. Болардан башка аның үзбәк театрлары өчен ясаган декорацияләре бар. Театр декорацияләрен эшләгәндә Х. Нафиков сәхнә спецификасын һәм автор идеяләрен тирәннән аңлап иҗат итә. Ул үз әсәрләре белән Бөтенсоюз, Бөтенроссия театр күргәзмәләренә авыр юлларны бик җиңел үтә һәм зональ күргәзмәләрдә үзенә күренекле, нык урын яулап ала.

Театр декорацияләре эшләү аны тарих белән кызыксынуга китерә. Татар халкының тарихы гаять бай, ә сәнгать әсәрләрендә ул җитәрлек яктыртылмаган. Х. Нафиков беренчеләрдән диярлек Болгар темасына мөрәҗәгать итә. Дөрес, аңа хәтле Болгар белән кызыксынучылар, хәтта аңа багышлап рәсем ясаучылар да булган. Болгар музеенда хәзер «Ибн-Фазланның Болгарга килүе» дигән Б. Урманче әсәрен, Р. Госмановның Болгар темаларына акварельләрен һ. б. күрергә мөмкин. Х. Нафиков Болгарның тарихын тирәннән өйрәнә, археологлар белән экспедицияләргә йөри.

Шушы вакытларның җанлы сурәтләрен без Х. Нафиковның «Болгар урамы», «Болгарда металл кою» (Европада беренче чуен кою мичләре тасвирланган), ак чатырлар, тирмәләр, сәүдә рәтләре тезелеп киткән «Ага Базар» исемле әсәрләрендә күрәбез. «Чичәннәр ярышы» дигән картинасында борынгы Казан, Кремль, хан чатыры, чичәннәр һәм халык шартлы рәвештә, миниатюра традицияләренә таянып ясалган.

Мөхәммәдьяр. XVI гасырда Казанда яшәгән шагыйрь. Безнең көннәргә аның «Төхфәи мәрдан» (Ир-егетләр бүләге) һәм «Нуры Содур» (Йөзләр нуры) дигән ике поэмасы килеп җиткән. Алардагы югары гуманистик идеяләр, гаделлек, яхшылыкка өндәгән фикерләр Мөхәммәдьярның зур каләм остасы булганын күрсәтәләр.

Х. Нафиковның «Мөхәммәдьяр» дигән әсәре, әлбәттә, бу шагыйрьнең шәхси портреты түгел. Бу әсәр шагыйрьнең иҗаты белән танышкач, художник күңелендә туган сәнгатьчә образ.

Хәнәфи Нафиков портрет сәнгатендә дә көчле, күпкырлы шәхесләр галереясын иҗат итә. Ул нәкъ шундый натураларны эзли, таба һәм ясый. Бу чыннан да көчле рухлы, югары идеяле, хезмәт сөючән кешеләр: шагыйрьләребез Г. Тукай һәм С. Рәмиев, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты шагыйрь Муса Җәлил, Советлар Союзы Герое, атказанган укытучы Умеркин А. С., Тукай премиясе лауреатлары скульптор Б. Урманче һәм композитор Р. Еникеев. Беренче татар актрисасы Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Татарстанның халык артистлары Х. Мәхмүтов һәм Г. Нуруллин.

Чәчәкләр. Хәнәфи Нафиков ясаган чәчәкләрне караганда кайсыдыр бер фикер иясенең «сынлы сәнгатьтәге чәчәкләр — ул күз белән күрелгән лирика» дигән сүзләре хәтергә килә. Хәнәфи натюрмортларындагы чәчәкләр нидер сөйли, җырлыйлар сыман. Алар күңелдә ниндидер сүз белән әйтеп бирә алмый торган тойгылар уяталар, хушландыралар.

Рәссамның авыл пейзажлары да бай колоритлы. Алар туган якны ярату тәрбияли торган әсәрләр. «Динис авылы», «Авылым иртәсе», «Туган авыл», «Мөрәле урамы» кебек хезмәтләрендә Х. Нафиков татар халык иҗаты традицияләренә таянып эш итә. «Яшьлек» дип исемләнгән әсәрендә рәссамның рәхәтләнеп, төсләр, төсмерләр, яшеллекнең санап бетергесез күп төннарын уйнатып алганын күрәбез.

Туган ягы Татарстан төбәкләрен Х. Нафиков үзе яраткан, ихтирам иткән якташлары портретларын иҗат иткән кебек олы мәхәббәт белән сурәтли. Х. Нафиков күп йөри, күп укый, уйлана, эзләнә. Үзе янында һәрвакыт кәгазь, карандаш, буяулар йөртә. Башка якларда йөргәндә дә ул үз халкына күрсәтер, аңлатыр өчен яңа пейзажлар, этюдлар ясап кайта. «Көньяк сериясе» дип исемләнгән Новороссийск, Бакчасарай яклары күренешләрен, «Казан сериясенең» В. И. Ульянов-Ленин белән бәйле урыннарын, академия театры, Шамил өе, Әҗем мәчете һ. б. рәсемнәрен күргәч, без киң карашлы, нык куллы рәссамның иҗат лабораториясенә кергәндәй булабыз.

Хәнәфи Нафиков — әсәрләренең югары идея һәм эстетикасын халыкчан ысуллар белән җиткерүче рәссам.


Флора ӘХМӘТОВА,
филология фәннәре кандидаты.




Мөхәммәдьяр.

Хәнәфи **НАФИКОВ** *әсәрләре*

Рөстәм МАНСУРОВ фотолары



Чичәннәр ярышы



«Түләк һәм Сусылу» операсына декорация эскизы.



«Алтынчәч» операсына декорация эскизы.

Борынгы Казанда сабан туе.



Халыклар дуслыгы — безнең сәхнәләрдә



Татарстан жыр һәм бию ансамбле башка республикаларның ансамбльләре белән даими багланышта яши. Алар арасында күптәннән инде чын мәгънәсендә дуслык элемтәләре булдырылган. Артистлар бер-берсеннән тугандаш халыкларның жыр-биюләрен өйрәнәләр һәм аларны үз коллективларының программаларына кертәләр.

Ансамбль артистлары Флера Кузина белән Ирина Елисеева Мордва биюен башкаралар. Бу бию «Сабан туе» дип аталган күренештә башкарыла.

Әйтергә кирәк, ансамбль артистлары программага кергән барлык биюләрне өйрәнергә, кирәк чакта бер-берсен алыштырырга тиешләр. Флераның тәжрибәсе зуррак, ул барлык биюләрне белә, Ирина яшьрәк әле, әмма ул да үзен талантлы артист итеп күрсәтте инде.

Ю. ФИЛИМОНОВ фотосы.

Бәясе 25 тиен.
Индекс 73002.